# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

3/ 2023

*Борынгы заманнарда ук, ата-бабаларыбыз күчмә халык булып тирмәләрдә яшәгәндә, торакны эчке яктан бизәү өчен басылган һәм тукылган келәмнәр, киезләр, чаршаулар көнкүрештә зур әһәмияткә ия булган. Мондый йорт кирәк-яраклары мул итеп чигелгән, аппликация һәм башка ысуллар белән бизәлгән.*








Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



# УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР!
## ИГРАЙ, ГАРМОНЬ!

**БЫЕЛНЫҢ 30 АВГУСТЫНДА БАШКАЛАБЫЗ КАЗАНДА РЕСПУБЛИКА КӨНЕ УҢАЕННАН «УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР!» XXXVIII РЕСПУБЛИКА ХАЛЫК ИҖАТЫ ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫ**

Татарстан премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев бәйрәмгә килүчеләрне сәламләп: «Без татар халкының көтеп алган, иң күркәм бәйрәме – Сабан туен бөтен өлкәләрдә, районнарда, авылларда гөрләтеп үткәрдек. Республика, Казан шәһәре көнен дә, елдагыча төрле өлкәләрдән оешмаларны җыеп, зур фестиваль оештырабыз. Бүгенге фестивальдә 30 өлкәдән 700 милләттәшебез катнаша. Сезгә татар җанлы булып, мәркәзебез Казанны, Татарстаныбызны туган җир итеп күргән өчен, безнең бәйрәмгә килүегез өчен зур рәхмәтемне җиткерәм», – диде.



«Татар халкы һәрвакытта да җырлы-моңлы булды: Илһамнарыбыз, Әлфияләребез, яшьләребез үзебезчә, милләтчә җырлый беләләр, авыр вакытта кәефне күтәрәләр. Шундый бәхетле, бердәм халык булып калыйк. Татарстаныбыз һәрвакыт, колачларын җәеп, каршы алсын, киткәндә дә, «Кайчан кире кайтасыз?» дип, үтенеп сорап калсын. Һәрберебезгә дә сәламәтлек, бәхет телим! Бәйрәм белән сезне!» – дип тә, өстәде ул.

Шулай ук Васил Шәйхразыев Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчелеге астында эшчәнлек алып баручы иҗат коллективларына тальян гармуннар тапшырды. Алар – Башкортстан Республикасы



Дүртөйле районыннан «Хәзинә» халык тальянчылар ансамбле, Балтач районыннан «Гармоника» гармунчылар ансамбле, Чүпрәле районыннан «Чүпрәле егетләре» халык гармунчылар ансамбле, Дондагы Ростовтан «Татар-башкорт мәдәни үзәге», Кукмара районыннан «Баламишкин» халык гармунчылар ансамбле, Балык Бистәсе районыннан «Чулман моңнары» халык гармунчылар ансамбле, Питрәч районыннан «Пимәр тальянчылары» халык ансамбле.

«Уйнагыз, гармуннар!» фестиваленең гармунчылар парадын быел Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова җитәкләде. Фестивальдә катнашучы гармунчылар, татар фольклор коллективлары Бауман урамындагы сәгать яныннан Казан Кирмәненә кадәр узды. Берничә җирдә, туктапып, халыкны биетеп тә алдылар. Казан Кирмәне территориясендә гармунчылар Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановны каршылады.



## ЭЧТӘЛЕК


**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**



4 **«Яңарыш: Дастанның заманча укылышы» фестивале**

6 **«Тузганакның да тамыры була»**

10 **III «Тормыш стиле – мәдәни код» фестивале**

**ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ**



12 Л. Фәсхетдинова **Татар чигүе**

**ҺӨНӘРЛЕ УЛМӘС...**



18 Р. Фәизова **Ак түбәдән Ак йортка**

24 Е. Шемелова **Милли чигү – борынгы бабаларыбызның мәдәни мирасы коды**



# Түгәрәк уен

№3 (49) / 2023


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*

*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълумати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 14.09.2023
Чыгу көне: 26.09.2023
Заказ: 067451 Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** Эскәтер фрагменты.
Элмәләп чигү. **Авторы Л. Фәсхетдинова**



© «Түгәрәк уен», 2023

ӘДӘБИ МИРАС




28 Л. Мөхәммәтҗанова **Татарларның аш-су табыны жырлары**


МИФОЛОГИК МИРАС


34 Г. Гыйльманов **Юрамышлар – мифларның анасы**


ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ




40 А. Әхмәтҗанова **Чабыр тау, Чабыр тау, Исемең мәңге калыр тау...**

44 М. Зәйнуллина **«Изгеләр чишмәсе»**


БЕЗГӘ ЯЗАЛАР




47 Ф. Нигъмәтҗанов **Бай күңелле Рифкать**

50 Н. Яхина **Әкияти Хызрата**


БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ





51 Т. Галиуллин **Мөнәҗәтләр – җан авазы**


БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...




54 Р. Шәйдуллина **«Эх, авылым кичләре»**

57 **Көзбай агай** (Җыр)


ӨЙ КҮРКЕ – АШ




58 **Казан кәлҗемәсе**


ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ


62 **Бергәләп бизибез!**




# «Яңарыш: Дастанның заманча укылышы» фестивале

Быелның 15-23 июль көннәрендә Болгарда «Яңарыш: Дастанның заманча укылышы» фестивале узды. Театрны һәм театраль эскизларны, төрле форматтагы концертларны, мода күрсәтүләрне, ярминкәләрне, укуларны үз эченә алган күп катламлы фестиваль булды ул.

Фестивальне шәрәфле кунак – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев ачып җибәрде, Рәхмәт хатлары тапшырды. «Без әле монда ни өчен җыелуыбызны азакка кадәр аңлап та бетермәгәнбездер. Без зур юл уздык. Хәзер яңа этап башлана, һәм сез аның беренче шаһитлары булачаксыз. «Мәдәни мирас» төшенчәсе гади әйбер түгел. Без хәзер мәдәни мирасны торгыза башлыйбыз. Вакыты җитте. Без әйткәнбез икән – эшлибез. Бүген сез саламда утырасыз икән, бу – шушы эшебезнең бер өлеше. Эшебез сүзебездән аерылмасын иде», – диде ул фестиваль сәхнәсеннән.

Фестивалнең беренче көнендә Болгар җирендә Татарстан Республикасының халык артисты Миләүшә Таминдарова җитәкчелегендә Татарстан Республикасының Дәүләт камера хоры, Татарстанның халык артисты Алинә Шәрипҗанова һәм Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова тарафыннан җырлар да яңгырады.





9 көн дәвамында Болгарда фестиваль гөрләде. Ул ачык һавада «Кара пулат» операсы белән тәгәлләнде.

Мәдәни программада төрле халыкларның театральләштерелгән дастаннары башкарылды.

«Ага базар»да 100дән артык һөнәрче үз товарларын тәкъдим итте.








Яңарыш:
***дастанның заманча укылышы***

# «Тузганакның да тамыры була»

Фестиваль кысаларында Карелиядән, Болгариядән, Кыргызстаннан һәм Якутиядән килгән театр труппалары дастаннар нигезендә куелган спектакльләр күрсәттеләр. Финалы – бишенче театр – ачык һавада күрсәтелгән «Кара пулат» операсы иде.

Карелиянең милли театры карел-фин халкының «Калевала» эпосы мотивлары буенча куелган «Куллерво» эпик драмасын алып килде. Спектакль 2 телдә барды – артистлар карел-фин теленең дә матурлыгын бирергә, өлешчә рус телендә дә уйнарга өлгерделәр. Музыка, яктылык, хәрәкәт, тел һәм эпосның сюжет байлыгы, хәтта бераз гына интерактив та – 1 сәгать 15 минутлык спектакльгә барысы да сыйды. Спектакльнең режиссеры – Карелиянең атказанган артисты Вячеслав Поляков.

Куллерво – «Калевала» эпосының бер герое, каршылыклы һәм бәхетсез герое. Яратылмыйча үсү һәм тәрбия булмау кешене нәрсәгә китерә – эпосның әлеге геройга багышланган өлеше шуны күрсәтә иде.

Бишкәк шәһәр драма театры «Манасчы» драматик кыйссасын күрсәтте. Ул «Манас» эпосының театраль тел белән заманча укылышы.





«Куллерво» спектакленнән күренешләр

Болгариянең Варна шәһәре «Тарихи паркы»нда тарихи вакыйгаларның реконструкциясе белән шөгыльләнүче команда «Кубрат хан васыятьләре» спектаклен алып килде. Спектакль Болгар музей-тыюлыгының «Хан сарае» конструкциясендә барды. Артистлар Кубрат хан улларының кыскача тарихын һәм корал белән эшли белү осталыгын күрсәттеләр.



«Манасчы» спектакленнән күренеш



*«Без Кубрат хан һәм аның 5 улы турындагы риваятьне алып килдек. Ханның уллары авыр вакытта аталары янына җыела. Хәзәрләргә бик авыр чорда борынгы Болгар белән ни буласын хәл итәргә кирәк була. Миңа Кубрат хан тарихы бик кызыклы. Идел буе Болгар дәүләте белән бәйләп тә өйрәндем. Алга таба 5 туганның һәрберсенең тарихын өйрәнеп, тарихи спектакль чыгарасым килә, чөнки шулкадәр бай тарих. Без профессиональ актерлар түгел. Без Урта гасырлардагы кылыч, ук-җәя, чыбыркы, балта белән эш итә белү осталыгын реконструкцияләп күрсәтәбез», – дип аңлатты труппа җитәкчесе* ***Пьер Леонард.***



**«Кыыс Дэбилийэ» олонхо спектакленнән күренеш**

Текст болгар телендә яңгырады, экранда рус телендә тәрҗемәсе барды. Финалда артистлар тамашаны «Алга!» «Без булдырабыз!» дигән татар сүзләре белән тәмамлады.

Чакырылган спектакльләрнең дүртенчесен – Якутиянең «Олонхо театры»ның «Кыыс Дэбилийэ» олонхо спектаклен Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев та карады. Спектакльне караганнан соң артистлар янына чыгып, аларга баш иеп рәхмәтен белдерде: «Булдырасыз! Булдырдыгыз! Без тарихыбызда шулай үз урыныбызны табып, бер-беребезгә күрсәтергә тиеш. Вакыт җитте! Элек күбрәк рәсми очрашулар булса, хәзер бәйрәм формасында очрашып, күзгә-күз карап, бер-беребезнең тарихи әсәрләребезне күрсәтеп бәһа бирергә кирәк», – диде ул.

Минтимер Шәймиев Россиянең күп милләтле дәүләт булуын ассызыклап, аның көче безнең бердәмлегебездә булуын татарча әйтте. «Тагын 1-2 спектакль карасам, телегезне аңлый башлаячакмын», – дип өстәде. «Олонхо театры» җитәкчесе Марина Турантаева Якутия Республикасының Дәүләт Киңәшчесе, «Олонхо театрына» нигез салган Андрей Борисовның сәламнәрен җиткерде, бүләкләр тапшырды.

Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова спектакль эчтәлегенә ишарә итеп: «Без тамырларыбызны барламасак, шулай аскы дөньяда калачакбыз», – диде. Министр катнашучыларга – Якутия һәм Болгария театрларына Дипломнар тапшырды.




**«Кубрат хан васыятьләре» спектакленнән күренешләр**





Фестивальнең тагын бер кызыклы театраль проекты – ГИТИС кураторлыгында оештырылган театраль лаборатория. Ул 2 әсәр нигезендә узды. Лаборатория эскизлары өчен Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» һәм Чыңгыз Айтматовның «Гасырдан озын көн» романы сайлап алынган иде.

7 режиссер һәм 40тан артык студент-артист атна дәвамында Болгарда яшәп, шушы 2 әсәр буенча эскизлар әзерләделәр.

**Ирада Әюпова:** *«Гасырдан озын көн» романы – мәдәни кодның югалу куркынычы, тамырлар белән элемтә югалу куркынычы турында. Болгардагы фестиваль безгә манкортка әйләнмәс өчен кирәк. Без үзебезнең кайдан килгәнебезне белеп яшәргә тиешбез. Шуның өчен – Чыңгыз Айтматов, шуның өчен Кол Гали. Быел Рөстәм Миңнехановның татар зыялылары белән очрашуында яңгыраган сорауларның берсе 2033 елда «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел, Кол Галинең тууына 850 булуына әзерлек турында иде. 10 ел бик тиз узып китә. «Кыйссаи Йосыф» әсәренең халкыбызга рухи байлыгын саклап калырга, балаларын-оныкларын тәрбияләргә булыша. Бүген әби-бабайлар белән балалар бергә яшәми. Балаларны интернет тәрбияли. Без бу трендны үзгәртә алмасак та, тәрбия концепциясе турында уйлансак иде. Бу фестиваль буыннар алмашы турында уйланырга этәргеч булсын иде. Тузганак буласы җайлы – өрдең дә очып китте. Әмма тузганакның да тамыры була».*





ГИТИС ректоры **Григорий Заславский:** *«Төрле «театраль мәктәп» белемле егетләрне-кызларны бергә, кыска гына вакыт аралыгында, нидер иҗат иттерү хөрмәткә лаек. ГИТИС студентлары белән Казан студентлары аралаштылар, дуслаштылар. Миңа бүгенге эскизларның дүртесе дә ошады. Һәрберсенең үз алымы бар иде. Әсәрне музыка аша, курчаклар аша, битлекләр аша аңларга тырышу да бар иде. Барысы да, миңа калса, уңышлы булды».*



Яңарыш:
*дастанның*
*заманча укылышы*

## III «Тормыш стиле – мәдәни код» фестивале

2 ел дәвамында Казанда узган халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать этно-fashion фестивале «Яңарыш: Эпосның заманча укылышы» фестивале программасына кергән иде һәм ул быел Болгар музей-тыюлыгының «Хан сарае» конструкциясендә дәвам итте. Изольда Сахарованың «Мисс Татарстана»







кызлары-егетләре күрсәткән этно-дизайнерларның модалы коллекцияләрен карарга Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев та килде. Этно коллекцияләрне күрсәтү «Бюро Бану» брендының «Риваять» коллекциясе белән башланып китте.

Фестивальдә Россия регионнарыннан барлыгы 63 дизайнер катнашты. Алар – Башкортстан, Чувашия, Марий Эл, Саха (Якутия) Республикасы, Ханты-Манси округы, Карелия, Самара өлкәсе, Красноярск крае, Иркутск өлкәсе, Пенза өлкәсе, Түбән Новгород өлкәсе, Краснодар крае, Ставрополь крае, Мурманск һәм Мәскәү шәһәрләреннән. Шулай ук 8 чит ил – Кыргызстан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Казахстан, Катар, Һиндстан һәм Бахрейннан дизайнерлар бар иде.













«Кара пулат» операсы да – фестивальнең матур бер финал өлеше булды. Быел ул кимендә мең ярым халыкны үзенә җыйды.

Спектакльне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова, ГИТИС ректоры Григорий Заславский, район башлыклары карады.









Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



**Калфаклар. Хәтфә, укалап чигү.**
**Авторы Л. Фәсхетдинова**

*Луиза ФӘСХЕТДИНОВА,*
*рәссам-этнограф*

# Татар чигүе



Татар чигүе, халык авыз иҗаты, көйләре, бәетләре, мифлары, әкиятләре һәм милли киемнәре кебек үк, халыкның рухын чагылдыра. Татар чигүчеләре күзаллауларындагы Коръәндә сурәтләнгән Фирдәүс җәннәте бакчаларын торгызучы хикмәтле үсемлек һәм чәчәк бизәкләре, җеп һәм тукыма төсләренең гаҗәеп кушылмасы – болар бар да татар чигүләре.

Борынгы заманнарда ук, ата-бабаларыбыз күчмә халык булып тирмәләрдә яшәгәндә, торакны эчке яктан бизәү өчен басылган һәм тукылган келәмнәр, киезләр, чаршаулар көнкүрештә зур әһәмияткә ия булган. Мондый йорт кирәк-яраклары мул итеп чигелгән, аппликация һәм башка ысуллар белән бизәлгән.

**Фәсхетдинова Луиза Фәһим кызы – Республикада декоратив-кулланма сәнгать өлкәсендә алдынгы рәссамнарның берсе, Россия рәссамнар берлеге әгъзасы (2002), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2018), Бакый Урманче исемендәге премия лауреаты (2022).**
**1968 елның 31 декабрендә Казанда туган. 1988 елда Казан сәнгать училищесын, 1998 елда Казан дәүләт университетының тарих факультетын, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспирантурасын тәмамлый. 1991 елда Бохарада укалап чигү фабрикасында укый.**
**Л. Фәсхетдинованың иҗат эшчәнлеге татар укалап чигү сәнгате традицияләрен яңарту һәм үстерү, татар чигү технологиясен үзләштерү (элмәле чигү һәм аппликация белән бизәкләү). Ул Татарстан сәнгатен күп кенә халыкара күргәзмәләрдә һәм фестивальләрдә күрсәтә. Луизаның әсәрләре Татарстан һәм Россия музейларында саклана, чит илләрдә дә хосусый коллекцияләргә сатып алынган.**



**Калфак. Хәтфә, аппликатив техника.**
**Авторы Л. Фәсхетдинова**

Тирмәне хатын-кызларның коруы һәм сүтүе дә мәгълүм, чөнки яугир ирләр башка мөһим эшләр белән мәшгуль булган. Куркыныч килгән очракларда хатын-кызлар тирмәне тиз генә сүтеп һәм төяп башка урынга күчерә алган. Табигый ки, торакларын бизәү белән дә хатын-кызлар шөгыльләнгән.

Яшәү урыны матур һәм уңайлы булсын өчен алар үзләренең бар зәвыкларын һәм хыялларын эшкә җиккәннәр, шулай ук көнкүрешкә һәм йолаларга караган әйберләрдәге, кием-салымдагы һәм башка бизәкләргә мәгънәләр дә салырга тырышканнар. Ул заман хатын-кызы өчен торак – аерым дөнья, һәр нәрсәсе үзара гармонияле яраша торган «микрогаләм» булган.

Соңрак, ата-бабаларыбыз утрак тормышка күчкәннән соң, аларның тораклары тирмәгә хас үзенчәлекләрне саклап калган. Бу интерьер бизәлешенең тукыма эшләнмәләргә бай булуында чагылыш таба. Торактагы җиһазларны каплап торучы бизәкле эшләнмәләр – чаршау, кашага, пәрдә, япмалар, дивар келәмнәренең күплеге менә шуннан килә. Моннан тыш, эскәтер, тастымаллар, япмалар, сөлгеләр дә чиккәннәр. Болар барысы да мул итеп чигүләр белән бизәкләнгән, өйне ямьләп, хуҗаларын сөендереп торган һәм саклагыч сыйфатын үтәгән.

Татар киемендә чигү аерым мәгънәгә ия. Чигү бизәкләрендәге һәр элементның үз билгеләнеше булган, ул кешене ят күзләрдән саклау яки аның дәрәҗәсен һәм социаль урынын чагылдыру вазифаларын үтәгән. Бизәк кәләш киеменә чигелгән очракта, саклагыч сыйфатыннан тыш, анда үзара мәхәббәт, бәхет һәм нәселне дәвам итү турындагы теләкләр чагылырга тиеш булган. Әгәр бала киемен бизәргә кирәк булса, анда һичшиксез күз тиюдән, чирләрдән, төрле явыз көчләрнең йогынтысыннан һәм башка саклагыч тамгалар урын алган.

Ислам кабул ителгәннән соң, мәҗүсилек күзаллаулары бөтенләй үк юкка чыкмый, аларга гарәп-мөселман мәдәни төсмерләре дә өстәлә. Халык чигү үрнәкләрендә гарәп графикасы элементлары һәм Коръәннән алынган символлар пәйда була.

Татар чигүчеләре үсемлек-чәчәк бизәкләрен XVIII гасырдан XX гасыр башына кадәрге чорда аеруча яратып кулланалар. Ислам кануннары буенча җан ияләре һәм кеше сурәтләрен ясау тыела, шуңа күрә дә татар орнаменты үсемлек-чәчәк бизәкләре юнәлешендә үсә. XVIII гасырда – XIX гасыр башында чигелгән композицияләр купшы, авыр, катлаулы бизәкләре, предмет тирәлеген тулысынча тутыручы бик күп бормалы детальләре булган, «көнчыгыш бароккосы» дип аталган стиль

**Намазлык фрагменты.**
**Элмәләп чигү.**
**Л. Фәсхетдинова күчермәсе**

**Намазлык.**
**Элмәләп чигү.**
**Авторы Л. Фәсхетдинова**

**Казан сөлгесе. Элмәләп чигү.**
**Реплика.**
**Авторы Л. Фәсхетдинова**









Ирләр баш киеме – такья. Хәтфә, укалап чигү.
Авторы Л. Фәсхетдинова

борынгылардан исәпләнә. Мәҗүсилек чорында кергән булсалар да, әлеге бизәкләр ислам дине тамыр җәйгәннән соң да татар сәнгатендә кулланылышта кала бирә.

Татар чигүендә иң борынгы һәм иң киң таралган үрнәкләрнең берсе – тормыш агачы сурәте, ул күп кенә халыклар сәнгатенә хас. Әлеге үрнәк төрле рәвештә: стильләштерелгән гади үсентедән алып, стильләштерелгән агачның кулларын күтәргән хатын-кыз образы белән тәңгәллеге кебек катлаулы сюжетка кадәр (кайвакыт бу үрнәк борынгы төрки алиһәсе Һомай белән тиңләштерелә) сурәтләнә ала. Мондый үрнәк борынгы укалы күкрәкчәләрне, Әстерхан татарларының (карагашларның) бәти савытларын *(янчык)* бизәгән.

Татар чигүендә тормыш агачы үрнәге чәчәк бәйләме рәвешендә сурәтләнә. Ул татар чигүенең барлык төрләрендә – кием-салымны бизәгәндә, дини табыну предметларында (намазлыклар, шәмаилләр) һәм көнкүреш әйберләрендә



Коръән савыты. Хәтфә, укалап чигү.
Авторы Л. Фәсхетдинова

сыйфатларын ала. Һәр хатын-кызның иминлеккә һәм муллыкка, нәселне дәвам итүгә омтылышын гәүдәләндерә. Биредә ислам шәрыгында орнаментка шул рәвешле мөнәсәбәтнең сәбәбе турындагы теория дә чагылыш таба – бизәкләр предметның бөтен өслеген алып тора. Бу – Аллаһының һәр нәрсәдә дә булуына ишарә, гүя Ул үзе белән бөтен киңлекне тутыра.

Әлбәттә, бүген без татар орнаменты семантикасын тулысынча торгыза алмыйбыз, безнең көннәргә борынгы бизәк үрнәкләренең мәгънәсе һәм мифологиясе турында тулы булмаган мәгълүматлар гына килеп җиткән. Шулай да кайбер мәгънәләрне һәм сюжетларны ачыкларга мөмкин.

Геометрик орнамент Казан татарларының XIX гасырга нисбәтле укалы түбәтәйләрендә файдаланыла. Болар – бауларга һәм «бәхет тѳеннәренә» охшаш зигзагсыман һәм дулкынсыман бизәкләр, шулай ук кояш билгеләре – «өермәле» розеткалар һәм «свастика» дип аталган тамгалар. Кояш билгеләре кояшны символлаштыра һәм иң

файдаланыла. Тормыш агачы тормышның эзлеклелеген, даимилеген, мирасны, байлыкны белдерә, шулай ук нәсел агачы *шәҗәрә* буларак та аңлатыла ала.

Чәчәк бәйләме үрнәге хатын-кыз калфакларын ука яисә энҗе белән бизәгәндә аеруча еш кулланыла. Ул симметрияле булырга да, алай булмаска да мөмкин. Симметрияле композицияләрдә Казан чигүләренә хас бер үзенчәлек күзәтелә – симметрияле булып тоелса да, ул барыбер махсус бозыла.

Калфак чигүләрендә тагын бер киң таралган үрнәк – *алтын каурый*. Ул өстенә бик вак детальләр – яфраклар, бөреләр, чәчәкләр, бөтеркәләр һәм мыекчалар тезелгән сорау билгесе сыман бөгелгән ботакчыктан гыйбарәт. Тулаем алганда, ул тылсымлы кош каурые кебек күренә. Төрки халыклар мәдәниятендә каурыйлар еш кына баш киемнәрен бизәгәндә файдаланыла.

Татарстан Республикасы Милли музее коллекциясендә тегеп чыгу ысулы ярдәмендә эшләнгән аппликатив чигү белән бизәлгән калфак бар (татар традициясендә – *чәмчә*). Калфакның иң очына кечкенә генә каурый кадалган. Шулай ук каурыйлар белән бизәлгән балалар түбәтәйләре дә очрый. Баш киемнәрендәге бу каурыйлар саклагыч сыйфатын үтәгән булса кирәк.

*Ай-йолдыз* үрнәге Казан татарларының XIX гасыр ахырына нисбәтле бәрхет калфакларында урын ала. Сәнгать белгече Р.Г. Шаһиева фикере буенча, йолдыз һәм ярымай үрнәге символик рәвештә гашыйк парларны гәүдәләндерә. Бәрхет калфакларда ярымай һәм йолдыз үсемлек-чәчәк орнаменты буларак стильләштерелә: йолдыз – стильләштерелгән канәфер чәчәге, ә ярымай урталай бөкләнгән яфрак кебек күренә.

Чигү үрнәге булган *парлы кошлар* калфакларда да, мәшһүр Казан сөлгеләрендә дә *(казан сөлгесе)*, пәрдәләрдә, ашъяулыкларда, алъяпкычларда һәм башкаларда да файдаланыла. Татар халык авыз иҗатында *парлы* сүзе «бәхетле пар» дигәнне аңлата, ягъни парсыз кеше бәхетле була алмый. Парлы кошлар – бәхет символы, ул күп кенә халыкларда бизәк үрнәге буларак билгеле.



**Калфак. Хәтфә, укалап чигү.**
**Авторы Л. Фәсхетдинова**

Казан татарлары чигүләрендә очрый торган тагын бер бик борынгы үрнәк – томшыгына «балчык»ябышкан кошчык. Бу сюжет риваятьләрдәге җир, дөнья океаны төбеннән үрдәк томшыгына ияреп чыккан балчыктан яралган дигән фаразлауларга барып тоташа. Шуңа охшаш кошлар чигелгән укалы бәрхет калфак Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана.

Татар чигүе – халкыбызның бай мәдәни мирасының аерылгысыз өлеше, шуңа күрә дә ул сакчыл мөнәсәбәткә мохтаҗ. Бүген Татарстан музейларында саклана торган иң борынгы чигү үрнәкләре якынча XVII-XVIII гасырларга карый, кызганыч ки, алар акрынлап туза бара. Музейларыбызда чигүле ядкәрләрнең кабатланмас үрнәкләре юкка чыкканчы аларның матурлыгы белән хозурланып калырга кирәк. Киләчәк буыннар да борынгы бабаларыбыз сәнгатен үз матурлыгында күрә алсын өчен аларның сыйфатлы күчермәләрен эшләп калдыру тагын да отышлырак булыр иде.

Фоторәсемнәр Л. Фәсхетдинованың шәхси архивыннан.
А.Титов фотолары

# Ак түбәдән
# Ак йортка

*Расиха ФӘИЗОВА,*
*журналист*



«Биюче»



«Гармунчы»



Самовар

БАЛЧЫК УЕНЧЫК ДИЮГӘ, НИГӘДЕР, БЕЗ КЕЧКЕНӘ ЧАКТА АВЫЛНЫҢ ШАЛАМА ҖЫЮЧЫСЫНДА ГЫНА БУЛА ТОРГАН КЫЗЫЛ БАЛЧЫКТАН ЯСАЛГАН СЫБЫЗГЫЛАР ИСКӘ ТӨШӘ. ЧҮЛМӘКЧЕЛӘРНЕҢ КАЛГАН «КАМЫР»ДАН ЭШ АРАСЫНДА ГЫНА ӘВӘЛӘГӘН СЫБЫЗГЫСЫН, «САНДУГАЧ»ЫН, «ГӨРЕЛДӘВЕК», «ШАЛТЫРАВЫК»ЛАРЫН КУЛГА ТӨШЕРҮ ӨЧЕН КҮПМЕ СӨЯК, ЧҮПРӘК-ЧАПРАК, КӘГАЗЬ ҖЫЕП ТАПШЫРГАНБЫЗДЫР – ИСТӘ КАЛМАГАН. ӘММА ШУЛ УЧ ТӨБЕНӘ ГЕНӘ СЫЯРЛЫК ЭЛӘ-ЧАЛА ГЫНА БИЗӘК ТӨШЕРЕЛГӘН, «ҮЗЕҢ ҖАН ӨРӘ ТОРГАН» УЕНЧЫККА КОШ ТОТКАНДАЙ СӨЕНҮЛӘР ӘЛЕ ДӘ ИСТӘ. БАЛА-ЧАГАГА «СЫБЫЗГЫ БОРЫННАР» ДИП СҮЗ КАТУ ДА ӘНӘ ШУЛ «СЫБЫЗГЫ БӘЙРӘМЕ» КӨННӘРЕНДӘ БУЛМЫЙМЫ ИКӘН ӘЛЕ?!.



**«Булат»**



**«Сөембикә улы белән»**



**«Әпипә» биюе»**



Җәмгыять җитәкчесе
Илсөяр Сәләхова

**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ БӨТЕН АСЫЛЫ – ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕ, ЙОЛАЛАРЫ, МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘРЕ, ФӘЛСӘФӘСЕ ГӘҮДӘЛӘНӘ БУ УЕНЧЫКЛАРДА. БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ ИГЪЛАН ИТКӘН СУВЕНИРЛАР БӘЙГЕСЕНДӘ ЮККА ГЫНА 70 ДӘГЪВА БЕЛДЕРҮЧЕ АРАСЫНДА ГРАН-ПРИГА ИЯ БУЛМАГАНДЫР УЛ.**

## ЧҮЛМӘКЧЕДӘН КҮРМӘКЧЕ...

Чүлмәкче кәсебе җир белән бергә яратылган дип әйтәбез икән, балчык уенчык та шул гомердән бирле адәм балаларының күңелен күрә торгандыр. Тик инде ул хәзер уенчык булудан туктап, теге яки бу төбәкнең визит карточкасы урынына йөри торган сувенир-брендка әверелде. Халык һөнәрчеләре иҗатының бу төрен гадәттә Дымково (Киров шәһәре), Емецк, Каргаполь (Архангельск өлкәсе), Торжок (Калинин), Иваново (Мәскәү өлкәсе), Мглин (Брянск), Филимоново (Тула) кебек бистә һәм шәһәр исемнәре белән бәйле рәвештә искә алабыз. Соңгы 31 ел эчендә Татарстанның Азнакай районындагы Актүбә бистәсе дә балчык уенчык җитештереп, татар экзотикасын чит кыйтгаларда танытучы төбәк буларак тарихка керде. 100 елдан артык тарихы булган «Дымково уенчыгы» янында үзен ышанычлы тотарга бөтен мөмкинлекләре бар «Актүбә уенчыгы»ның. Милләтебезнең горурлыгы булган каюлы читек, көмеш чулпы-алкалар, тамбур җөйле «Казан сөлгесе», укалы калфак, түбәтәйләр янында «Актүбә уенчыгы»дай рухи арадашчы булырлык (халыкара товар билгесе булган!) үз сувенирың булу зур мәртәбә. Татар дөньясының бөтен асылы – гореф-гадәтләре, йолалары, милли бәйрәмнәре, фәлсәфәсе гәүдәләнә бу уенчыкларда («Әбием сандыгы», «Сәкедә чәй эчү», «Яучылар», «Чишмә буенда», «Каз өмәсе», «Сабан туе», «Мәчет» һәм башкалар). Бөтендөнья Татар конгрессы игълан иткән сувенирлар бәйгесендә юкка гына 70 дәгъва белдерүче арасында гран-прига ия булмагандыр ул. Татар дөньясын колачлый алуы һәм татар сувениры таләпләренә тулысынча җавап бирүе белән кызыклы бу эшләр. Борынгы Болгар тарихыннан башлап, XIX гасыр азагына кадәрге чорны әйтерсең бер сулышта «уйнап» күрсәтә «Актүбә уенчыгы».

Бүген «Актүбә уенчыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять Актүбә сәнгать мәктәбе урнашкан бинаның өченче катын биләп тора. Биредә барлыгы 11 кеше эшли. Лариса Костюкова, Даша Зыкова, Розалина Хаҗиева, Регина Хаҗиева һәм башкалар кебек, күптәннән бизәк төшерүчеләр булып эшләгән һөнәрчеләрне югары бәялиләр монда. Яңа гына эшкә урнашканнар нәкъ менә аларның кул астында осталыкка өйрәнә. «Кемнең кулы эшкә ятып тора, кемнеке юк – шундук күренә», – диләр кызлар.

Эш бүленгән: берәүләр булачак сыннарны калыпларга салып, билгеле бер сәгатькә кадәр чыныкканын, кипкәнен көтә. Аннан әлеге шикәр кебек ап-ак эшләр бизәк төшерүчеләр хозурына күчә. Элек җирле чимал, ягъни ак балчык белән эш иткән булсалар, соңгы 15 елда скульптура гипсына күчкәннәр. «Балчыкның сыйфаты без теләгәнчә түгел», – дип аңлата алар моны.

## ГАЛИЯБАНУ, ӘЛМӘНДӘРЛӘР МОНДА ДА БАР

– Тарихи үткәнебез иҗат канатымның бер ягы булса, икенчесе – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры репертуарындагы спектакльләр. Шуларга нигезләнеп, күп фигуралы 100дән артык сюжет эшләнде. Элек уенчыкларны күбәйтү турында уйламадык. Шуңа күрә дә, нигездә, эксклюзив эшләр башкара идек. 31 еллап шулай дәвам



«Очрашу»



«Казан татарлары»



«Хәдичә ханым»



«Хохлома» самовары



«Чәй эчү»



«Гжель» самовары



«Балалайкачы»

итте. Ягъни без аларны калыпка салып түгел, ә һәркайсын аерым әвәләп башкардык. Әмма бу бик кыйммәткә төшә. Аннан аларны кабатлау да бик авыр, – ди «Актүбә уенчыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять җитәкчесе Илсөяр ханым Сәләхова.

Әйе, кемнәрне генә ясамаганнар: йөзьяшәр Әлмәндәр карт та, Әҗәлетдин дә, Галиябану да бар монда. «Эксклюзив» тамгасы астында башкарылып, үз ияләренә тапшырылганнарының исемнәре генә дә күптән инде 500дән артып киткән. Ә эшләнгән барлык сувенир 350 мең (!) данә булыр, диләр. Күпләп җитештерелә торган сувенирлар исә 100 төрдән дә артык икән. Араларында татар халык әкиятләренә корылган сюжетлы сыннар да байтак. Эх, шуларны каникулга авылга кайткач кечкенә оныгы – Илсөяренә төннәр буе әкиятләр сөйләп чыккан Дәрига әбисе күрсә, ни дигән булыр иде икән? Чатыра авылы әбиләрен җыеп килеп күрсәтми калмас иде, мөгаен. Илсөяр ханым да үзенең тәүге эшләрен әбиләргә күрсәткән. «Кайлардан безне шулкадәр белеп ясыйсы иттең?» – дип, исләре киткән әбекәйләрнең.

Шунысы кызык: һәр эшнең бер данәсе, ә «эксклюзив» дип аталганнарының фотосурәтләре кала икән.

«Актүбә уенчыгы» җәмгыяте оешканнан бирле биредә «Россиянең халык сәнгате һөнәрләре» музее да эшләп килә. 7 ел элек ул зурайтылган. Музейның иркен, якты өч залы бар. Биредә нинди генә чит ил делегацияләре, нинди генә мәртәбәле кунаклар булмаган. Күпне күргән ил агалары да, мондагы могҗизага таң калып, «Теләкләр дәфтәре»нә әллә никадәр җылы сүзләр язып калдырганнар. «Сезнең фидакярлекне күреп сокландык. Татар сәнгатен торгызу юлында болай эшләгәч, иншалла, халкыбыз да яшәр. Шушы изге эшегездә бинаһая зур уңышлар теләп, дога кылабыз», – дип язган мәшһүр җырчыбыз Илһам ага Шакиров. «Киләчәгегез бик өметле. Сез, бүтәннәргә матурлык бүләк итү белән беррәттән, үзегезнең укучыларыгызда



зур зәвык тәрбиялисез. Бүгенге ыгы-зыгылы дөньяда сезнең иң зур бурыч – кеше рухын саклап калу», – бу сүзләр Туфан ага Миңнуллиннан.

## ИСКЕ АВЫЗДАН ЯҢА СҮЗ КӨТӘЛӘР

Укучыларга килгәндә, бүген Актүбә сәнгать мәктәбендә чыннан да скульптура, керамика, кулланма-гамәли сәнгатькә аеруча басым ясала. Хәзер инде махсус кулланма-гамәли сәнгать сыйныфы да булдырганнар. Элегрәк бизәк төшерүгә ныграк игътибар биргән булсалар, хәзер әвәләп ясауга басым ясыйлар, чөнки мондагы яңа идеяләр өченче каттагы һөнәрчеләр өчен дә бик кызыклы. Ягъни иске авыздан яңа сүз көтә остазлар. Ә балаларның фантазияләре чиксез. Остазлары да ни җитте генә түгел шул! Һөнәрчеләр балаларга гына түгел, өлкәннәргә дә, башка районнардан килгән кунакларга да мастер-класслар үткәрәләр.

## ДӨНЬЯ ТАР УЛ

«КИЛӘЧӘГЕГЕЗ БИК ӨМЕТЛЕ. СЕЗ, БҮТӘННӘРГӘ МАТУРЛЫК БҮЛӘК ИТҮ БЕЛӘН БЕРРӘТТӘН, ҮЗЕГЕЗНЕҢ УКУЧЫЛАРЫГЫЗДА ЗУР ЗӘВЫК ТӘРБИЯЛИСЕЗ. БҮГЕНГЕ ЫГЫ-ЗЫГЫЛЫ ДӨНЬЯДА СЕЗНЕҢ ИҢ ЗУР БУРЫЧ – КЕШЕ РУХЫН САКЛАП КАЛУ», – БУ СҮЗЛӘР ТУФАН АГА МИҢНУЛЛИННАН.

Моны «Актүбә уенчыгы» гел дәлилләп тора. Ни дисәң дә, Актүбәдән Американың Ак йортына – элеккеге Президенты Билл Клинтонга кадәр барып җиткән уенчык бит ул. География елдан-ел киңәя бара. Англия, Франция, Мисыр, Австралия... нинди генә кыйтгалар юк бу исемлектә. Үз йөзен күрсәткән сувенирын тотып, халкыбыз үзе юл саба чит җирләргә.

– Менә бу тәлинкәнең тарихы бик кызык, – ди Илсөя ханым. – Лениногорск шәһәреннән килгән заказчыбыз: «Миңа шундый итеп ясагыз – анда Казан да, Германия дә, Лениногорск та булсын», – ди... Баксаң, аның кызы Германия кешесенә кияүгә чыккан икән. Кияү испан короленең туган тиешлесе, ди. Менә шундый булгач, кая гына китми дә, кемнәргә генә барып эләкми безнең эшләр...

Шунысы кызык: «Актүбә уенчыгы»ның бәһасен аңлап, аның һәр яңа эшен көтеп алучы коллекционерлар да барлыгы мәгълүм.

Ислемай кибетенә керсәң – исе йогар, тимерче янына керсәң – итәгеңә чаткысы төшеп, итәгең янар, диләр. Ә «Актүбә уенчыгы» җәмгыяте остаханәләреннән чыкканда азмы-күпме акшарга буялып, өс-башыңа бояу исе сеңдереп чыксаң да гаеп түгел. Биредә уенчык ясауның уен түгел, ә ниндидер бер җылы хискә чорналган, конвейерга корылган бик җитди, үтә җаваплы, четерекле эш булуын тоясың. Сынлы сәнгатьне кеше күрә торган шигърият белән чагыштыруның ачык мисалыдыр бу. Күңелдә бер сорау туа: Дымково, Каргаполь, Филимоново уенчыклары кебек безнең күңелләргә якын булган «Актүбә уенчыгы»н да чит җирләрдә таныйлармы икән?!.

Фоторәсемнәр И. Сәләхованың шәхси архивыннан

ӨЧ БАЛА АНАСЫ ГӨЛНАРА РАВИЛ КЫЗЫ НУРМӨХӘММӘТОВАНЫҢ БӘХЕТЛЕ ТОРМЫШ СЕРЕ – НЫКЛЫ ГАИЛӘДӘ, ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ КЫЙММӘТЛӘРЕН ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРЕН САКЛАУДА ҺӘМ ТОРГЫЗУДА, КЕШЕЛӘРГӘ ЭЧКЕРСЕЗ БУЛЫШУДА.

# Милли чигү – борынгы бабаларыбызның мәдәни мирасы коды



Гөлнара Нурмөхәммәтова, «Казан сөлгесе» остаханәсе җитәкчесе

Мин тумышым белән Киров өлкәсенең Ноктар аланы шәһәреннән. 11 яшемдә гаиләбез әтинең туган ягына – Кукмара районының Адай авылына күчеп кайтты. Һәр торак пункты, кешеләр кебек, үз холкы һәм үзенчәлекләре белән аерылып тора: мәсәлән, Адай, мәдәни традицияләрне, һөнәрчелекне саклавы белән үзенчәлекле. Класс-ташларымның әти-әниләре барысы да традицион һөнәрчелекне дәвам итеп, итек басканнар. Халык йолалары һәм гореф-гадәтләре турында да мин нәкъ менә шушы авылда белдем. Һәр татар йортында матур вакыйгага әверелгән «Каз өмәсе» йоласын да биредә күрдем. Бу бит каз эшкәртү генә түгел, аралашу да, күңел ачу да, осталыгыңны күрсәтү дә. Безнең гаиләнең казлар тотуы да минем теләгемнән башланды. Без дә авылдашларны җыеп шушы борынгы йоланы үти идек.

Өлкән сыйныфларда укыганда кызлар белән Сабан туена кульяулык чиктек. Чигү өчен бизәкләрне бер-беребездән сер итеп саклый идек. Чигү төренә килгәндә, шома чигү иде, читләрен ыргаклы энә белән челтәрләдек. Сабантуйдан тыш, чиккән кульяулыкларны солдатка китүче егетләргә дә бүләк итә идек. Көрәш батырына бүләк итү өчен яшь кәләшләргә Сабантуйга сөлге чигештек. Сүз уңаеннан, шуларның берсе – көрәш буенча дөнья чемпионы, халыкара класслы спорт мастеры




АЕРУЧА ЗУР ГОРУРЛЫГЫБЫЗ – АЛЪЯПКЫЧЛАР. БЕЗДӘ АНЫҢ ҖАНЫҢ ТЕЛӘГӘН ТӨРЛЕСЕ БАР – КАНАТЛЫЛАРЫ ДА, КАНАТСЫЗЫ ДА, БӨРМӘЛЕСЕ ДӘ, ГАДИЕРӘГЕ ДӘ, АГЫ ДА, ТӨСЛЕСЕ ДӘ...





Азат Нурмөхәммәтов белән соңрак гаилә кордык. Димәк, күпмедер дәрәҗәдә безне Сабантуй сөлгесе кавыштырды дия алабыз.

Кыскасы, Кукмара районы минем өчен татар һөнәрчелеге, традицияләре һәм йолалары мәктәбе булды.

Мәктәпне тәмамлагач, Казан (Идел буе) федераль университетының журналистика факультетында укыдым, Татарстан радиосында эшләдем. Гаилә корып, балалар тугач, декретта утырганда сөлге чигә башладым – өемне татар мәдәнияте элементлары белән бизисем килде. Милли бизәкләрне интернеттан, басма чыганаклардан таптым, бизәкләр иҗат иткән дизайнерлар белән аралаштым.

Чигүнең күңелем тарткан эшем икәнен, алга таба да шөгыльләнәсем килгәнен шунда аңладым. Шулай итеп шәхси эшмәкәр булып киттем, аннары үзмәшгульлек белән «Казан сөлгесе» остаханәсе ачып җибәрдем.

Без тамбурлы һәм шома чигү белән сөлгеләр, ашъяулыклар, намазлыклар чигәбез. Аеруча зур горурлыгыбыз – алъяпкычлар. Бездә аның җаның теләгән төрлесе бар – канатлылары да, канатсызы да, бөрмәлесе дә, гадиерәге дә, агы да, төслесе дә... Кайчандыр алъяпкыч авыл кешесенең милли киеменең бер өлеше булган. Хәзер дә чигелгән алъяпкыч бик кулай бүләк, ул теләсә кайсы яшьтәге хатын-кызны бизи, теләсә нинди аш бүлмәсен матурлый, көндәлек эшне дә бәйрәмгә әверелдерә.

Безнең остаханәдә шома һәм тамбурлы чигү машинкалары бар. Бу эшләнмәләребезне арттырырга мөмкинлек бирә. Ләкин бизәкләр







МИН ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫНЫҢ БОРЫНГЫДАН КИЛГӘН КУЛ ЭШЕ БУЛГАН ЧИГҮНЕҢ ТОРГЫЗЫЛУЫНА ШАТЛАНЫП ТУЯ АЛМЫЙМ – БЕЗНЕҢ ОСТАХАНӘБЕЗ ДӘ МОҢА ҮЗ ӨЛЕШЕН КЕРТӘ. ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ ҺӘМ ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ ХӘЗЕР ҮЗ ЮГАРЫЛЫГЫНА ИРЕШТЕ.







шаблон белән ясалмый, аларны дизайнерлар иҗат итә. Кул белән чигелгән әйберләребез дә бар – аларны өйләрендә эшләүче осталардан сату өчен алабыз.

Мин татар хатын-кызының борынгыдан килгән кул эше булган чигүнең торгызылуына шатланып туя алмыйм – безнең остаханәбез дә моңа үз өлешен кертә. Татар халкының милли һөнәрчелеге һәм декоратив-гамәли сәнгать хәзер үз югарылыгына иреште. «Печән базары» яңа татар мәдәнияте фестивале башланган чорда без башкалабыз кунакларына тәкъдим итәрдәй милли сувенирларыбыз да юк иде. Хәзер алар мул.

Мин балалар бакчаларында милли чигү буенча дәресләр дә үткәрәм. Әлбәттә, инә белән эш итмибез, кием яки көнкүреш әйберләре макетына бизәкләр ябыштырабыз. Бу балаларның милли сәнгать белән беренче танышуы.

Тормышымны бәхетле иткән тагын бер юнәлеш – хәйриячелек. Күп еллар дәвамында авыр тормыш чатаклыгына юлыккан хатын-кызларга ярдәм кулы сузам. Аларга ярдәм итеп, нәтиҗәсен күрү – зур бәхет.

Алдагы планнарымда – татар бизәкләрен тагын да тирәнтен өйрәнү, һәр элементның мәгънәсенә төшенү, аларны эштә куллану һәм башкаларга да өйрәтү. Милли чигеш һәм милли бизәкләр – борынгы мирасыбызның мәдәни коды.

**(«Татфолк. Новый формат» (2023 ел, 4 нче сан) газетасыннан алынды. Авторы Евгения Шемелова)**

Фоторәсемнәр Г. Нурмөхәммәтованың шәхси архивыннан

# Татарларның аш-су табыны җырлары

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының*
*баш фәнни хезмәткәре*



**Татарларның җыр сәнгатендә лирик җырларның кунак төшерү, каршы алу, озатып калу, аш-су табынында җырлана торганнары аерым урын алып тора. Бу төр җырларда татар халкының милли характерына хас күркәм сыйфатлары – кунакчыллыгы, дусларча тату яшәүгә, кардәшлек һәм бердәмлек тойгыларына хөрмәте чагылыш тапкан. Кунак табыны, якыннарны бергә җыйган аш-су мәҗлесе, гаилә бәйрәме яисә гомумән туганнар һәм дусларның аралашып бер табын артында утыруы гадәттә җыр белән үрелеп бара торган булган. Табын җырлары татарларда бүгенге көндә дә гаять актуаль. Моңлы да, борынгы да җырларның төрле уңай белән уздырыла торган татар мәҗлесен әле безнең көннәрдә дә ямьле һәм кызыклы итүе – татар мәдәнияте белән таныш һәркемгә мәгълүм.**

Табында хуҗа һәм кунакларның бер-берсенә матур теләкләр белән җыр әйтешүе һәм күмәк җыр – төрле төбәктә яшәүче татарларның һәр төркеменә, шул исәптән, керәшен татарларына хас күренеш, ата-бабалардан калган матур традиция. Табын җырлары Татарстанның Мамадыш, Балык Бистәсе, Кукмара, Мөслим, Зәй районнары керәшеннәрендә, Чиләбе өлкәсе нагайбәкләрендә бүген дә актив яши, мәҗлес барышында тоташ яңгырап, табынны тагын да күркәм итә.

Татар җырлары арасында аш-су табыны җырларына галимнәр тарафыннан зур игътибар һәрвакыт бирелеп килә. Мәсәлән, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Г.М. Макаров, К.М. Миңнуллин, И.Ш. Кадыйров һәм башкаларның экспедиция нәтиҗәләрен чагылдырган хезмәтләрендә алар аерым урын били. Җырларның мондый төре соңгы чорда Казан фәнни үзәкләре – Татарстанның мәдәният ресурс үзәге, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан дәүләт консерваториясе, Казан федераль университеты галимнәре тарафыннан шактый күп язып алынган. Аш-су табыны җырларын махсус рәвештә

туплап, системага салып, халыкка чыгаруга омтылыш ясаучы галимнәр дә бар. Мәсәлән, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты доценты Зоя Николай кызы Кириллова тарафыннан керәшен этник төркеме вәкилләреннән язып алынган җырлар матбугатта дөнья күрде[1]. Галимәнең шәхси архивында исә җырларның әлеге тематик төркеменә керә торганнары «Табын җырлары» дигән исем белән теркәлгән[2].

«Аш-су табыны җырлары» дип билгеләнә торган шигъри текстлар Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 2000 еллар башыннан оештырып килә торган комплекслы фәнни экспедицияләр вакытында тупланган материаллар арасында да бик күп булуы белән характерлы. Әлеге үрнәкләр – татарлар яши торган төрле төбәкләрдә язып алынган, аш-су табынына бәйле лирик иҗат.

Аш-су табыны җырларын тематик төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин. Мәсәлән, «Кунак каршылау җырлары», «Олылар (өлкән яшьтәге аеруча ихтирам казанган кунак) хөрмәтенә җырлар», «Туганнар һәм дуслар хөрмәтенә җырлар», «Аш бирү җырлары», «Тау итү (ашаган-эчкәнгә рәхмәт әйтү) җырлары», «Табында туган-тумачага, хуҗаларга җырлау», «Ит, бәлеш һәм башка ризык чыгарганда җырлау», «Кунакны озатканда җырлана торган җырлар» кебек төркемнәр аш-су табыны белән бәйле башкарыла торган җыр иҗатын тулысынча диярлек сыйдыра.

Жанр төре үзе дүрт юллык строфалардан гыйбарәт. Әлеге строфаларның һәркайсы шартлы мөстәкыйльлеккә ия. Шуңа күрә тематик гомумиләштерүләр дә шактый шартлы. Аш-су табыны җырлары билгеле бер төбәктә, гадәттә, аш-су мәҗлесе вакытында язып алына. Информантның үзе тарафыннан табын җырлары, әлбәттә, югарыда аталган төркемнәргә бүленми, шул ук вакытта бер төркемгә нисбәт ителгән җырның, мәҗлес вакытында ситуация-җаена карап, темага ярашлы рәвештә теләсә кайсы төркемдә башкарылуы ихтимал.

Халыкның күп гасырлар дәвамында чарланган һәм һәр мәҗлес өчен дә диярлек уртак булган җырлары гадәттә озын көйгә башкарыла, кыска көйгә җырлана торганнары да бар. Әй-



**Л. Мөхәммәтҗанова Азнакай районы Сарлы авылында информантлар белән**

[1] Кириллова З.Н. Казан арты керәшеннәренең табын җырлары // Чын мирас. – 2012. – № 4 (июль). – Б. 70-75.
[2] Табын җырлары. Кириллова З.Н. Шәхси архив / Татарстанның Балык Бистәсе районы Казак Чаллысы авылында Дмитриева Евдокия Ивановнадан (1939 елгы) З.Н. Кириллова тарафыннан 2012 елда язып алынган.



**Э. Галимова, Л. Мөхәммәтҗанова Азнакай районы Урсай авылында информантлар белән**

тик, озын көйгә җырлана торган 10–9 шигырь үлчәмле дүртьюллыклар, кыска көйгә башкарыла торган 8–7 үлчәмлеләре, шулай ук аралаш-катнаш үлчәмле текстлар очрый. Башкарылу мәсьәләсенә килгәндә, җырлар арасында кыска үлчәмле җырлар төрле ярдәмлекләр яки эмоциональ ымлыклар кушу хисабына озын көйгә дә җырланырга мөмкин. Башкаруга хас мондый үзенчәлек табын җырларына гына түгел, татар халык җырларының башка төркемдәгеләренә мөнәсәбәттә дә актуальлеген югалтмый.

Аш-су табыны җырлары гадәттә беренче зат исеменнән башкарыла, «мин» яисә «без» исеменнән лирик геройның хис-кичерешләре, теләк-омтылышлары хакында сөйли, җырлаучы яисә күмәк башкаручыларның һәрберсе өчен уртак һәм аңлаешлы булуы белән характерлана. Болар – лирик иҗат булуларыннан тыш халыкның гореф-гадәте, йола бәйрәмнәре белән тыгыз бәйләнгән иҗат төре. Төрле сәнгать башлангычларының йола һәм сүз сәнгате белән үрелгән борынгы формасын фәндә әдәби-сәнгати (художестволы-сәнгати) синкретизм дип йөртелүе мәгълүм. Аш-су табыны җырларына да, аларда лирик тезмә һәм көй төп рольне уйнаса да, синкретик иҗат булу сыйфаты хас, ягъни лирик җырларның бу төрендә йоладан тулысынча аерылып бетмәгәнлек тә бар.

Татарларның аш-су табыны җырларын әдәби сүз сәнгате буларак кына түгел, аның көе, башкарылу үзенчәлекләре белән бергә кабул итү һәм җыр сәнгатенең үзенчәлекле төре дип бәяләү мөһим. Бу төр иҗатка халык иҗатын сүз сәнгате буларак тикшерүче фольклорчылар белән бергә этномузыка белгечләренең дә зур әһәмият бирүләре мөһим.

Бүгенге санга туплап бирелә торган җыр текстлары – үзенең лирик табигатьле булуы, отып алырга һәм башкарырга җиңеллеге белән халык хәтеренә тирән уелган, асылы белән халкыбызның матур традицияләре хакында искәртеп тора торган кыйммәтле мирас. Җырларның язып алыну ареалы шактый киң, информантлар төрле. Биредә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы фәнни экспедициядә 2017 елда Татарстанның Мөслим районы Яңа Усы авылында Митюшкина Елизавета Алексеевнадан (1978 елгы), Григорьева Сөмбел Мөхәммәтхафиз кызыннан (1977 елгы), 2016 елда Чиләбе өлкәсе Нязепетровский районы Париж авылында Батраева Екатерина Дмитриевнадан (1969 елгы) Л.Х. Мөхәммәтҗанова; 2012 елда Балык Бистәсе районы Казак Чаллысы авылында Дмитриева Евдокия Ивановнадан (1939 елгы), Кириллова Александра Федоровнадан (1949 елгы) З.Н. Кириллова; 1998 елда Казан дәүләт

консерваториясе Әстерхан өлкәсенә оештырган фәнни экспедициядә Володар районы Тулугановка авылында Ажниязова Римма Фәхретдин кызыннан (1937 елгы), Якупова Ханидат Тимерсолтан кызыннан (1937 елгы), Каражанова Ханият Джулман кызыннан (1930 елгы), Красноярский районы Ясын-Соккан авылында Үтәголов Исмәгыйль Бикбай улыннан (1913 елгы), Харабалинский районы Лапас авылында Суйналиев Сагындык Ережеповичтан (1936 елгы) консерватория галимнәре тарафыннан язып алынган материаллардан кайбер үрнәкләр сайлап бирелде.

## КУНАКЛАРНЫ КАРШЫ АЛУ ҖЫРЛАРЫ

Кырга чыксам, исем китә
Алма агачы июләрен,
Үземә үзем хәйран булам
Сезне күргәч сөенүләремә.

Ишектән керә килдегез,
Исәнләшә белдегез;
Руза гөлчәчәге кебек
Күземә күрендегез,

Хуш килдегез, кода-кодагыйлар,
Хәерле булсын туегыз,
Сезне көтә-көтә, гой,
Сузылды, гой, ай муеныбыз.

Ишектән керүләрең лә
Елмаеп көлүләрең;
Әллә нидән артык булды
Сезне бер күрүләре.

Каян килдегез сез безгә,
Батмыенча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итим сезгә?

Җырлап ачыла күңел ди,
Җырлап ачыла күңел;
Җырлап ачылмаса күңел,
Мәңге яшьләчәк[3] түгел,

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Энҗе-мәрҗән кебек тезелеп.
Сез туганнарны көтеп алдык
Ах, үзәкләребез өзелеп.

Айлар идек без ай идек,
Агыйделләр кичеп килдек без,
Агыйделләр кичеп, суын эчеп,
Бер күрешер өчен килдек без.

Кырга чыксам, исем китә
Алма агачы иелүләренә.
Үземә үзем хәйран булам
Сезне күргәч сөенүләремә.

Бүген мичләрем сүрән булган,
Пешмиенчә калган минем бөккәнем.
Яндый тәрәзәләрдән күзем алмый,
Сез булдыгыз минем көткәнем.

Базарларга барсам,ниләр алыйм?
Алыйм микән әллә ал калфак?
Сез киләселәрен белгән булсам,
Барган булыр идем ат яллап.

Каралты түбәләрем ачылды
Бастырмалар куйгач, басылды.
Килгәннән бирле карап торам,
Сез барыгыз да шушылай асылмы?

Әй утырыйк, утырыйк ла,
Өстәл өстен тутырыйк;
Ашап эчү бер дип түгел,
Бер җырлашып утырыйк.

## АШ БИРҮ ҖЫРЛАРЫ

Олы юлга чыккан идем,
Ак калфаклы кыз килә.
Өстәл өсләрен ямьләндереп,
Ипи белән тоз килә.

[3] Яшьләчәк – яшәрәчәк

Кибетләргә кердем, пәке алдым,
Кисим дип агач башларын.
Аякларга басып, кул чәбәкләп,
Каршы алыйк кодалар ашларын.

Әй түрендә садыгыз,
Садыгызда – атыгыз.
Бу дәүләтне, бу хөрмәтне
Ничек тартып килде атыгыз?

Әй төче бал, төче бал,
Төче балдан була әче бал.
Безнең кодаларның өстәлендә
Ни ашыйсың килсә, шулар бар.

Иртә торып тышка чыксам,
Очрады миңа гаетче.
Безнең сыйларыбыз бары шунда,
Сез булмагыз инде гаепче.

Йөгерә-йөгерә жыярларга
Юл буенда юа юк.
Сездә ничек, бездә шулай
Гаеп итә торган йола юк.

Биек тауның башларында
Әйләнәдер минем башларым.
Тәмле-татлы итеп сез ашагыз –
Сезнең өчен пешергән ашларым.

Биек тауның башларында
Әйләнәдер минем башларым.
Бу кем ашлары дип сорасагыз,
Шушы кодаларның ашлары.

Түтә-түтәл кәбестә,
Орлыккае урыста.
Бу ашаганны, бу эчкәнне
Без бирмибез бурычка.

Өстегезгә кигән алъяпкычның
Алмаларын тигез төшергән.
Безләр киләсене сезләр белгән,
Тәмле-татлы ашлар пешергән.

Алъяпкыч баулары ал тасма,
Бәйли-бәйли торам бит.
Никләр ашамыйсыз, никләр эчмисез –
Каршыгызда җырлап торам бит.

Карлыганнар ашар идем,
Ашасам, тешләрем камаша.
Килгәннән бирле карап торам –
Сезнең аш бирүегез тамаша.

Актый сыерларның сөтен саудым
Базар прәннекләре ясарга,
Безгә ходай шуны язсын –
Бергә-бергә ипекәй ашарга.

Ашасым килә, әй, әллә ни
Табаларда пешкән хәлвәне,
Җаннар йөретә, әй, гәүдәне,
Ризыккай йөртә, әй, бәндәне.

## ТАУ ИТҮ ҖЫРЛАРЫ (АШАГАН-ЭЧКӘНГӘ РӘХМӘТ ӘЙТҮ)

Биек тауның башларында
Ак җәймәләр кордым ау итеп.
Бу җырларны без җырлыйбыз
Ашаган-эчкәнгә тау итеп.

Безләр монда ник килдек? –
Ашар-эчәр өчен дип килдек.
Ашаган-эчкән гомер тормый,
Бер күрешер өчен дип килдек.

Язлар житәр, кошлар сайрар,
Ишетер микән Нуриәхмәт.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Алла риза булсын, бик рәхмәт.

Иртә торып тышка чыксам,
Ап-ак кырау төшкән шомыртка.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Дәүләт иңсен иде бу йортка.

Биек-биек тауның чиясе,
Исән, жиргә тиясе.
Бай да булсын, сау да булсын
Бу ашларның иясе.

Агыйделнең суында
Сусар коенадыр саенда,
Атна тотсак та, ай тотмабыз,
Җибәрербез сагынган саен да.

Мичкә лә мичкә балыгыз,
Мәскәүләргә киткән danыгыз.
Мичкәләрдә балыгыз бетмәсен,
Башыгыздан дәүләтләр китмәсен.

Безнең урам озын урам,
Уртасында кыл күпер.
Җаннарың ярып бирмәссең инде
Шушы сыйларыгызга бик шөкер.

Ишек алдым яшел чирәм,
Оекчаннар чыгып таптарбыз.
Монда ашаган, монда эчкәнне
Илебезгә кайткач, мактарбыз.

Елтыр-елтыр итәдер,
Ат өстендә ыңгырчак.
Бу ашаганны, бу эчкәнне
Кайтарырбыз микән бер-бер чак.

И ашыңа, туганым, и ашыңа
Дәүләт яусын синең башыңа.
Бүдәнәләр кебек юргалашып,
Бәхетләрең килсен каршыңа.

Шыбыркай да шыбыр тамчы тама
Баскыч башындагы ташыңа.
Берләр шөкер түгел, меңнәр шөкер
Безне хөрмәт иткән ашыңа.

Урамнардан үтеп барган чакта
Борылыпкай кердем өеңә.
Ашадыккай, эчтек, хөрмәт күрдек
Тау итүем шушы сыеңа.

**КУНАК ОЗАТУ ҖЫРЛАРЫ**

Сандугачлар микән, ай, кагынган,
Карлыгачлар микән кагынган?
Очкылыккай тотса, тот исеңдә:
Без булырбыз сине сагынган.



Агыйделләр коя кара Иделгә
Кара Идел коя диңгезгә.
Әз гомернең эчләрендә
Сүз китерешмик берләр беребезгә.

Әле дә күрдем, ай, мин сезне,
Тагы да кайчан күрермен мин сезне?
Итләрем бетсә, калыр сөягем,
Шул чакта да онытмам мин сезне.

Еракtan якты күренә
Чистай кибетенең йозагы.
Сезнең белән шушылай йөрешергә
Килсен иде гомернең озагы.

Өй артына кошлар килгән,
Кумагыз, куркытмагыз,
Бергә булган вакытларны
Аерылгач та онытмагыз.

Челтәрләр элдем читәнгә
Җилфер дә җилфер генә итәргә
Кунаклар йөри китәргә
Белмим ни хәлләр генә итәргә.

Киртә өсләрендә киртәдер
Китмә, туганаем, иртәдер.
Китмә, туганаем, иртәдер,
Сез киткәчтен ямьнәр бетәдер.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# Юрамышлар – мифларның анасы



*Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,*
*язучы, әдәбият белгече*

ЮРАМЫШЛАР – МИФЛАРНЫҢ ИҢ КИҢ ТАРАЛГАН ЖАНРЫ. АНЫ МИФЛАРНЫҢ АНАСЫ ДИП ТӘ ӘЙТЕРГӘ МӨМКИН. ЧӨНКИ ХАЛЫКНЫҢ РУХИ МИРАСЫНДА САКЛАНЫП КАЛГАН ҺӘР ЮРАМЫШ НИГЕЗЕНДӘ НИНДИДЕР МИФ, РИВАЯТЬ, ЫРЫМ-ЫШАНУ ЯТА. ӘЛБӘТТӘ, ЙӨЗӘР, МЕҢӘР ЕЛЛАР ҮТКӘННӘН СОҢ, КҮП КЕНӘ ЮРАМЫШЛАРНЫҢ МИФЫН, ВАКЫЙГАСЫН, МӘГЪНӘСЕН КҮЗАЛЛАУ НЫК КЫНА АВЫРЛАШКАН, ЕШ КЫНА АНЫ КҮЗАЛЛАП, ТАНЫП, ШӘРЕХЛӘП-АҢЛАТЫП ТА БУЛМЫЙ.

Шулай да, турыдан-туры мифларга алып чыккан юрамышларны бүген дә халык телендә очратабыз. Әйтик, халыкта «Урманда кычкырып көлсәң – адашасың (диванага сабышасың, Шүрәле кытыклап үтерә һәм башкалар)» дигән юрамыш-әйтем бар. Хәзер Шүрәле хакындагы мифларны искә төшерәсе генә кала: урманда Шүрәле карты очраса, теш күрсәтергә (көләргә) ярамый. Аңа теш күрсәтсәң (көлсәң-елмайсаң), ул: «Моның көләсе килә икән бит, туктале, көлдерим әле үзен», – дип, кытыклар өчен генә яралган озын бармакларын уйнатып, кешене дивана иткәнче, хәтта үлгәнче кытыкларга керешә, имеш... Адашу хакындагы юрамыш та мифлар белән дәлилләнә: урмандагы түбән рухлар (урман ияләре, шүрәлеләр, ярымтыклар, албастылар...) кешеләрне еш кына урмандагы кайтавазлар (әйе, урманның үз кайтавазы бар) белән адаштыралар. Әйтик, кеше кычкырып көлә, ә бу көлү, кайтаваз булып, кабат кайтып ишетелә. Кеше, үзе дә сизмәстән, «Кем бар икән?» дип кызыксынып, шул кайтаваз артыннан урман төпкеленә кереп китә һәм... адаша. Бу юрамыш-ышануны «Шүрәле кешеләрне, тавыш биреп, урманда әйләнгечләтеп, миңгерәүләтеп, адаштырып йөртә» дигән мифик сюжет берәмлеге белән дә дәлилләргә мөмкиндер.

Тагын шул хакта гына искәртәсе кала: еш кына бу юрамышны җырлар белән дә бәйлиләр: «Урманда кычкырып җырласаң – зиһенең зәгыйфьләнә».

Юрамышларның формуласы бик гади: нәрсә булса – шул була, яисә: нәрсә эшләсәң – шул була. Борынгы дәверләрдән килүче тагын бер юрамыш-

ны шәрехләп карыйк. Борынгылыкта очлы башлы, үткен әйберләр, бигрәк тә кораллар (сәнге, ук, кылыч, пычак, хәнҗәр һәм башкалар) ир затына тәңгәлләштерелгән, ирлек билгесе буларак каралган. Ә менә йомры, түгәрәк, җәлпәк, куыш эчле әйберләр, бигрәк тә аш-су кораллары, хатын-кызлык билгесе, хатын-кызлар символы булып йөргән. «Пычак (чәнечке) төшсә – ир-ат килә», «Калак-кашык төшсә – хатын-кыз килә» дигән юрамыш-әйтемнәр шуннан калган.

> «Йөзәр, меңәр еллар үткәннән соң, күп кенә юрамышларның мифын, вакыйгасын, мәгънәсен күзаллау нык кына авырлашкан, еш кына аны күзаллап, танып, шәрехләп-аңлатып та булмый.»

Юрамышлар нигезендә, һәр мифик жанрдагы кебек, ышану ята. Һәм бу ышану күп дәверләр буе сыналып, хәтта үзенчә дәлилләнеп килгән ышану, инану булган. Ул гына да түгел, безнең бабаларыбыз бу юрамышларны еш кына аксиома рәвешендә кабул иткәннәр һәм шул дөньялык яисә табигать кануннары буенча яшәргә тырышканнар. Хәтта аларны тормыш-көнкүрештә үзләренә буйсындырырга, һич булмаса практикада кулланырга тырышканнар. «Йомырка юрамышлары» дигән ышанулар системасын гына алыйк. Гомумән, йомырка (күкәй) белән бәйле мифик берәмлекләр, йолалар, нигездә, уңыш, иген уңышы белән бәйләп каралган. Бу ышанулар юрамышларга да төшеп калган. Менә шундый берничә юрамыш:

Утырган тавыкның беренче өч йомыркасын алалар да юрый башлыйлар: әгәр беренче йомырка авыррак булса – чәчүгә иртә төшәргә кирәк; икенче йомырка авыр тартса – чәчүгә уртача төшәргә кирәк; өченче йомырка авыррак булса – чәчүгә соңлабрак төшсәң дә ярый. Бу юрамышның башка вариантлары да бар: беренче йомырка авыр булса – иртә чәчкән ашлык уңа, икенче йомырка авыррак булса – урталыкта чәчелгән иген уңа, өченче йомырка авыр килсә – соңгы чәчкән ашлык уңа... Беренче йомыркага карап кына юрау да бар: йомырка тотарга авыр тоелса – иген уңа, таманча булса – иген уртача булса, тотарга гадәттән тыш җиңел тоелса – иген уңмаячак...

Юрамышларның тәгәл системасы булган. «Йомырка юрамышлары»нда без моңа инандык инде. Тормыштагы һәр күренеш, һәр предмет яисә җан иясе юралган. Шулай яшәргә җиңел булган. Күренешләрнең, әйберләрнең мәгънәсе хакында өр-яңадан уйланып, аларны кат-кат сынау-дәлилләүгә караганда, әзер юрамыш калыпларына мөрәҗәгать итү җайлырак бит...

Әйтүебезчә, борынгы кеше өчен иген игү, икмәкле, ризыклы булу имин яшәешнең иң мөһим шарты булган. Юрамышлар ситемасында иң күп ышанулар әнә шул игенчелек гаме белән бәйләнгән дә инде. Менә «Салам юрамышлары»ннан бер мисал: «Ел башы буласы төндә һәр ашлыкның саламын кар астына куеп калдырып, бер атнадан алып карыйсың. Кайсы ашлыкның саламы бүрткән булса, шуны күбрәк чәчәргә кирәк». Тагын бер йола: «Елның беренче төнендә, чүмәләдән башлы арыш алып, карга кадап куясың. Шул арыш башагы иртәнгә бәсләнсә – арыш уңар».

«Кырмыска юрамышлары»н да шушы тип ышануларга кертергә мөмкиндер. Менә аларның иң популяры: «Яз көне кырмыскалар оясына барасың да нәкъ уртасына, кырмыскаларга зыян ясамыйча гына, таяк тыгып куясың. Таякка кырмыскалар күпме менсәләр – иген шул биеклектә үсәр».

Йорт-җир, өй, гаилә иминлеген өй катына килгән, өй түбәсенә кунган кошлар белән юраганнар. Бу шулай ук үзе бер мифологик система. Бу мифик берәмлекләрнең дә кайчандыр үз мифлары булган, әлбәттә. Кайберләрен бүген дә аерым-ачык танып, белеп була, кайберләре хакында фаразларга гына туры килә. Менә аларның берничәсе:

Йортка ябалак килеп кунса – бәла-казага.

Йорт түбәсенә саескан кунса – салкынга; өйгә дә салкынлык керә, якын кешеләр арасында мөнәсәбәтләр бозыла. Әгәр йорт түбәсенә кунган саескан ямьсез каркылдаса – начар (авыр, кайгылы) хәбәр (хат) булачак.

Өй түбәсенә тукран кунса – зур кунак киләчәк; ул әйбәт хәбәр яисә сөенче алып килә.

Өй түбәсенә козгын килеп кунса – бәхетсезлеккә; йортка, анда яшәүчеләргә бәла-каза килә.

Яз көне өй катына пар сыерчык кунса – парлы буласың.

Өй катына кәккүк иянәшсә – балалар белән бәйле борчу-кайгылар буласын көт тә тор!

Мондый юрау системалары (темалары) йөзгә якынлаша. Алар, үз чиратында, ниндидер зуррак темаларга берләшәләр. Әйтик, димләү, килен, кияү, туй барышы, никах белән бәйле юрамышларны бер сүз белән «Туй юрамышлары» дип әйтергә булыр иде. Бу темага картотекада биш йөзгә якын юрамыш бар. Табигать күренешләре, ел фасыллары, һава торышы, хайваннар-җәнлекләр, малтуар, кош-корт, бөҗәкләр, үсемлекләр, йорт-җир, гаилә, бала-чага, аш-су (ризык, табын), кием-салым, кыяфәт (бу юрамышлар, «Кыяфәтнамә» исеме астында тупланып, күләмле трактатлар барлыкка китерәләр), гомер (яшәү, үлем), бәхет-бәхетсезлек, мәхәббәт, уңыш (җиңү), холык, әхлак һәм башкалар бик күп гомумиләштерелгән темалар белән бәйле юрамыш системалары бар. Бу темалар арасында күз тиюдән, зәхмәттән, авыру-чирләрдән саклану юрамышлары аерым урын тота.

Халык ышануларында, күп очракта, юрамышта бирелгән хәл әхвәлгә шәрехләмәләр дә тәкъдим ителә. Бу бигрәк тә кара юрамышлар, явыз рухлар белән бәйле ышанулар юралганда бик мөһим; борынгы ата-баба ерак оныкларына әлеге кыен хәлдән чыгу юлын да әйтеп калдырырга тырышкан, күрәсең. Әйтик, гап-гади хәл: барган җиреннән җигүле ат туктап кала. Мондый хәлне нәрсәгә юрарга? Бу очракта бел дә тор: юлыңа сихер-зәхмәт кергән. Ат шуны сизгән, хәтта күргән (җир өстендәге җен-шайтаннар дөньясын җан ияләреннән бары тик атлар гына күрә ала дигән халык ышануын кая куясың?!). Менә шуннан соң рекомендацияләр башлана: нәрсә эшләргә?

1. Саламга ут төртеп, ат алдына ташларга кирәк. Шулай иткәндә шайтан (зәхмәт) качып китә, имеш.

2. Ат туктаса – тимер алып, ат, чана, арбаларны тимер белән сызгаларга кирәк. Тимер белән сызган чакта сихер дигәннәре мәче (кара мәче) булып чыгып китә, имеш.

3. Ат туктаса – балта алып, аның очы белән ат-арба тирәсендә түгәрәк сызып чыгарга кирәк. Соңыннан балтаны шул түгәрәк эченә кадап куясың да белгән догаларыңны укыйсың яисә куак яки салам төсләтәсең.

4. «Әгузебисмилла»ны әйтеп, догалар укып, ат тирәсендә йөреп чыгарга кирәк.

Халыкта элек-электән «Гыйшык юрамышлары» популяр булган. Аларны еш кына кара магия, сихер, шаукым йолалары системасында карыйлар. Кеше ирләрен (ярларын) үзеңә карату, көнләшеп, үч итеп, сөйгән ярларны аеру, гаиләләрне күрәләтә бозу, таркату белән бәйле юрамышларны турыдан-туры кара шаукым белән бәйләргә мөмкиндер. Менә шундыйлардан берничә мисал: Кемнең дә булса чәчен, сагыз белән әвәләп, утка атсаң – сиңа үлеп гашыйк булачак, ягъни, «сагыз кебек ябышачак». Мунча тире җыеп, аны камырга кушып, яраткан, күзең төшкән кешеңә ашатсаң – ул мәңгегә синеке булачак һәм башкалар.

«
Сынамышлар табигатьтәге климат, һава торышы, ел фасыллары белән бәйле үзгәрешләрне күп дәверләр буе сынау нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Икенче төрле әйткәндә, күпьеллык сынау юрау булып, бәхәссез нәтиҗә булып әверелгән.
«

Юрамышлар турында сүз алып барганда шуны да искәртергә кирәк; мифологиядә аңа бик якын торган, тугандаш жанрлар да бар: тыюлар, фаллар, сынамышлар. Тыюлар хакында сүз булды инде. Алар юрамышларның кире логикасын белдереп (формуласы: бу гамәлне кылырга ярамый, чөнки шулай-шулай була), бары тик тыю тәгълиматына гына кайтып калалар. Фалларның нигезендә юрамышлар ята, әмма алар инде, гадәти юрамыш кәлимәсеннән үсеп чыгып, бөтен бер йолага әверелеп киткәннәр. Сынамышлар табигатьтәге климат, һава торышы, ел фасыллары белән бәйле үзгәрешләрне күп дәверләр буе сынау нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Икенче төрле әйткәндә, күпьеллык сынау юрау булып, бәхәссез нәтиҗә булып әверелгән. Чынлыкта, кешелек яшәеше белән бәйле юрамышлар да шундый сынау юлы белән барлыкка килгәннәр.

Хәзер журнал укучыларына халык телендә киң таралган, гадәти татар гаиләсе тормышында мөһим роль уйный торган кайбер юрамышларга мисаллар тәкъдим итәбез.



## ЯҢА ТУГАН БАЛА ЮРАМЫШЛАРЫ

Бала елап туса – моңлы була.

Бала «битлек» белән туса – бәхетле була, юлбашчы, хаким була.

Бала «күлмәк» белән туса – озын гомерле була.

Бала теш белән туса – нәфесле була.

Бала сөйләнеп туса – тәмле телле була.

Бала, туганда, учларына кан кыскан булса – усал була, яугир була; учында кан булмаса – тыныч, басынкы, юаш кеше була.

Бала сыерчык килгәндә туса – теле тиз ачыла.

Бала язын кошлар кайтканда туса – күп сөйләшүчән була (яки: җырчы була).

Бала туган йортта бер үк вакытта бия дә колынласа – бу бала каһарман-батыр булып үсәр, күп эшләр башкарыр, күп батырлыклар эшләр.

Баланың кендеген кыска киссәң – сигәк була.

Баланың кендеге эчкә баткан булса – елак була.

Баланың кендеге югалса – явыз була.

Баланы беренче мәртәбә бишеккә салганчы, аңа кадәр бәләк яки тукмак салсаң – бала таза була. Шуңа күрә дә борынгылар баланы яшерен тел белән «тукмак» дип йөрткәннәр.

Буш бишекне тибрәтсәң – бала елак (авыру) була.

Баланы бишектә ялгыз калдырсаң – җен-пәри, шайтан алыштыра, бала авырый башлый, бозыла.

Яңа туган балага, башка ризык ашатмыйча, кырык көнгә кадәр ими генә бирсәң – бала гомере буе әнисе янында калачак.

Яңа туган баланы бал һәм май белән авызландырсаң – ул йомшак һәм татлы телле булып үсәр.

Баланың соңгылыгын пычрак урынга күмсәң – бала авырый.

Баланың яткылыгын җиргә сай күмгәндә – бу хатын бик еш бала табачак; бик тирән күмгәндә – сирәк табачак; йөзтүбән каплап күмгәндә – ул хатын бала табудан туктый.

Яңа туган баланың кашына көмеш тәңкә белән сызсаң – кашы нечкә була һәм башкалар.



## САБЫЙ БАЛА ЮРАМЫШЛАРЫ

Балалары үлеп торган ата-ана яңа туган балаларын сигез тишектән уздырса – башка үлмәячәк.

Балалары үлеп торган кешеләрнең яңа туган баласын кендек әбисе, өй тирәли әйләндереп, тәрәзә аша алып керсә – бала озын гомерле булачак.

Кара күзле бала бик елак була.

Сабый бала карт кешегә карап көлсә – бу баланың гомере озын булыр.

Бер яше тулмыйча баланың тырнагын киссәң – ул каты авырый башлый (яисә үлә).

Бишектәге бала көзге белән уйнаса – акылга зәгыйфь була.

Баланы аягын тотканда (йомышын йомышлатканда) үпсәң – авызы сасы була.

Ут белән уйнаган бала сигәк була.

Бала атасының башы, чәчләре, сакал-мыеклары белән уйнаса – атасы башына уйный.

Бала күмер ашаса – гомере кыскара.

Теле ачылыр вакыт җиткән баланы сыерчык оясы астына алып чыгып утыртсаң – теле ачыла. (Бу юрамыш «Сыерчык балаларга тел алып килә» дигән ышану белән бәйле. Билгеле булганча, сыерчык – телгә бик тиз өйрәнә ала торган кош.)

Балага гел йомырка (күкәй) ашатып торсаң – теле озак ачыла, тавык кебек, «ти-ти» килеп кенә тора, ди.

Баланың керләрен тукмак белән тукмап юсаң – бала елак була (яисә гомере буе тукмалып яши) һәм башкалар.



## ТУЙ, НИКАХ ЮРАМЫШЛАРЫ

Кияү кергәндә кызга энәле әйбер кадатсалар – яшь гаиләдә татулык булмаячак.

Кияү-кәләш өстәленә (алдына) пычак-чәнечке куйсалар – татулык булмаячак.

Кияү кергәч, кыз кияүнең бүреген салдырып, үз башына кисә – тормышта иренә баш була.

Кияү-кәләш кергәч, кайсысы беренче булып икенчесенең аягына баса – шул гаиләдә өстен була. (Варианты: кайсы, беренче булып, аяк астына җәелгән келәм өстенә баса, шул өстен була.)

Килен төшкәндә, яучы, кодалар, капкадан чыккач, уң якка борылып китсәләр – юл уңышлы, яшь гаилә бәхетле була.

Кыз кияү йортына күчкәндә артына борылып караса – ата малы (бәхете) кызга күчә, кыз белән китә, имеш. (Кияүгә киткән кыз нигез йорттан чыкканда артына әйләнеп караса – аерылып кайтачак, дигән вариант та очрый.)

Килен арбадан яңа йортка төшкәндә, җиргә мендәр салып, авызына бал-май каптырсалар – адымнары йомшак, теле татлы булыр.

Яшьләргә никах укыган вакытта янда торган суны эчкән кыз бәхетле була.

Никах укыганда кыз югары җирдә торса – бәхетле була.

Кызга башкода (яучы) булып барган ир кеше ишектән чыгуга ук уң чалбар балагың итек кунычына кыстырса – кызны тиз бирәләр.

Никах укылып беткәч, кызның башына көтмәгәндә сөт өсте салсаң – яңа йортта аның ыруы бәхетле була. (Сөт – нәсел, ыру, кавем билгесе.)

Яшь килен, кияү йортына килгәч, аттан төшкәндә шул атның сыртына таянып төшсә – тормышы мул, бөтен була.

Яшь килен төшкәндә, кулын, аягын юдырып, суны нигезгә сипсәләр – нигездә бәрәкәт булыр. Килен исә бу йортта бик тиз үз кеше булып китәр. Нигез иясе аны бик тиз кабул итәр.

Яшь килен төшкәндә, бигрәк тә аттан төшкәндә, аның кулын онга батырып, шул онны сәдакага бирсәләр – йортта муллык, байлык булачак.

Яшь килен беренче утырышта кияүдән ерак утырса – аралары ерагая, суына, татулык югала (араларына шайтан керә).

Яшь киленнең беренче китергән суы өйгә керткәндә түгелеп-чәчелеп бетсә – тормышы бәхетсез була. (Сирәк кенә: «байлыкка, бәрәкәткә», дигән юрамыш-ышану да очрый.)

Яшь килен көянтәсен сындырса – тормышы җимерелә.

Яшь килен, «әни», «әти» димичә, каенатасы белән каенанасына исемнәре белән әйтсә – теше авыртачак, яисә: авызы шешәчәк.

Яшь килен кияүгә кушылган төндә йокласа – мәхәббәт булмый.

Кияү кергән кичне кияү белән кызның кайсы элек йокыга китсә, шул элек үлә.

Курчак белән күп уйнаган кызларның балалары күп була.

Яшь килен көзгесенә карасаң – яшәрәсең.

Көйгән камыр ашарга яраткан кызның туенда буран булачак.

Караңгыда качып ризык ашарга яраткан кызның кияве карак була.

Кыз кеше өйгә тәрәз аша кереп йөрсә – кияве карак була.

Кыз кеше ботканың маен читкә агызса – кайнанасы сукыр була.

Чынаякларын тутырып ясап эчкән кызларның бәхете тулы була.

Толымнарын очына кадәр үреп йөргән кызга мәһерне аз бирәләр.

Самавыры, миче тиз үрләмәгән кызның кияве булдыксыз була.

Таба ялаган кызның кияве таз була.

Иләк аша караган кызның кияве шадра була.

Кыл иләк аша караган кызның кияве кылый була.

Көзгегә карап ашаган кызның кияве көнче була.

Тәрәзәгә карап ашаган кыз читкә китеп каңгырачак (яисә: шушы арада яучы киләчәк).

Көзгесен ваткан кызның тормышы уңышсыз була.

Көзгесен югалткан кызның ире икенче хатынга китәчәк.

Кыз белән егет сөйләшкәндә сабый бала төчкерсә – кавышуга.

Аш өстәле артына, ялгышып, ике кашык алып утырган кыз кияүгә бик тиз чыгачак.

Өстәл почмагына утырган кыз кияүгә соң чыга (яисә: җиде ел чыкмый). Шуны ук егетләр хакында да әйтергә мөмкин.

Суган ачысына еламыйча түзә алган кыз каенанасына да түзәр һәм башкалар.



## ӨЙ, ЙОРТ-ҖИР ЮРАМЫШЛАРЫ

Өй нигезенә типсәң, суксаң – нигез рәнҗи, корый. Ә синең аягың тартыша башлый.

Өйне эчендә бура калдырып салсаң – бу йорттан үлем китми. Чөнки өй эчендәге бураны кабер белән тиңләгәннәр. Өй эчендә бурадан өй салып уйнарга да ярамаган.

Ишек аркылы, тупса аша күрешсәң – кулың корый. Ишек аркылы әйбер алсаң да – кулсыз каласың...

Тәрәзә төбенә яисә ишек тупсасына утырсаң – үсмисең (яисә: бөкре каласың).

Койма ауса – өй хуҗасы үлә.

Тәрәзә башыннан яисә өй түбәсеннән кош оясы төшсә – кайгыга, бала кайгысына.

Тәрәзә чатнаса (ватылса) – бу йортка күз тигән (яисә: хуҗа кешегә күз тигергәннәр).

Тәрәзә аша йөргән кызларның (малайларның) ирләре (хатыннары) карак була.

Морҗа кирпече төшсә – өйдән җылылык китә, татулык-бәхет бетә.

Йортның беренче нигез ташын кыз кеше салса – җылы була.

Йорт салганда өйнең дүрт почмагына бакыр акчалар куйсаң – бу йортта бәрәкәт, иминлек, байлык булыр.

Өй салганда стенага корыч кыстырсаң – явыз рухлар якын килми.

Өй ишеге башына ярканат канаты кыстырсак (каксаң) – шайтаннар, явыз рухлар кермиләр, урын буш түгел икән, дип кире китәләр. Чөнки ярканатлар халык телендә «шайтан иярченнәре» булып йөриләр.

Хатыны үлеп тол калган кеше, кабат өй салырга туры килсә, нигез бүрәнәләрен хатын-кыздан тәгәрәттергән. Шулай иткәндә ул икенче мәртәбә тол калмый, имеш.

Яңа йортта беренче кырык көн эчендә бер генә мәртәбә булса да ялгыз кунсаң – синең яныңа шайтан керә, сине албасты баса, җен алыштыра һәм башкалар.



## ЮЛ-СӘФӘР ЮРАМЫШЛАРЫ

Мичкә тыгылган ипи ярылып чыкса – юлга.

Чәч үргәндә бер бүлеге үрелми калса – юл була.

Чәч юлын кыек ачсаң – юл уңмый.

Берәр кешене кыскарак юлга озатканда, пар чынаякларга тутырып чәй ясап калдыралар – шулай иткәндә ул исән-сау кайта, аның юлы уңа, диләр. Мул, тулы әйбер белән кайта, дигән ышану да бар.

Юлга чыгучы кеше өйдә үзенең сыныгын калдырса – тиз әйләнеп кайтачак, сәфәре уңышлы булачак. Өйдә бу сыныкны саклап тотарга тиешләр. Моның нигезендә «ризык тарту»га ышану ята.

Юлга чыгучы матчага икмәк сыныгы кыстырып калдырса да – ризыгы аны исән-сау йөртеп алып кайтачак.

Юлга чыгучы бишектәге баласын өч тапкыр әйләнеп чыкса – исән-сау йөреп кайтачак.

Кемне дә булса юлга озаткач, буш кул белән керсәң – юлга чыккан кешенең юлы уңмый. Бер кочак утын булса да күтәреп керергә кирәк.

Юлга чыгучының артыннан ук идәнне, чоланны, ихатаны, капка алдын себермәскә киңәш итәләр. Югыйсә сәфәрдәге кеше ачуланып, тузынып кайта. (Тузан туздыру бу очракта тавыш-ызгыш чыгаруга тиңләштерелә.)

Юлга чыгасы кешенең кулын онга батырып, шул онны сәдакага бирсәң – бу кешенең юлы уңачак.

Юлга чыгар алдыннан мәче аякларыңа сырпаланса – начарлык көтелә. Юлга чыкмавың хәерлерәк.

Юлга чыгар алдыннан мәчене сыйпап куйсаң – юлың уңачак.

Юлга чыгар алдыннан эт уласа – юлың уңышлы булачак.

Юлга чыгар алдыннан эткә ризык бирсәң – юлың уңачак.

Юлга чыгар алдыннан өйдә бала еласа – сәфәреңне кичектереп тор. Бала тынычлангач кына кузгал.

Юлга чыгар алдыннан ике пар чиләккә түгелер-түгелмәс итеп су тутырып куйсаң – юлың уңар.

Юлга чыгар алдыннан тәрәзә өлгеләрен юсаң, юлың уңар, исән-сау әйләнеп кайтырсың.

Берәр кеше, юлга җыенганда, киемен кире (сул) ягы белән кия башласа – юл уңачак.

Юлга чыгучыга хатыны күлмәгеннән җеп алып бирсә – юлчы исән-сау әйләнеп кайтачак.

Юлга чыкканда юл өстендә яткан себеркене атлап чыгарга ярамый, югыйсә афәткә юлыгасың. Кайбер якларда: көянтәне атлап чыгарга ярамый.

Юлга кузгалганда ат беренче булып уң аягын атласа – юл уңачак.

Юлга чыгасын кеше үзе дә сәфәрен уң аяктан башларга тиеш.

Берәр кешене озатканда, артыннан озак карап калсаң – киткән кеше озак кайтмый торыр.

Юлга чыгучы үбеп китсә – исән-сау кайтмавы бар. Шуңа да борынгылар озатышканда үбешергә кушмаганнар.

Юлга чыккач мәет очраса – юл уңмый.

Юлга чыккач тулы йөккә очрасаң – юл уңа.

Юлда барганда ат туарылса – юл уңмый.

Юлда барганда таш, балчык кисәкләрен типкәләп барсаң – юлың уңмый (яисә: бәла чакырасың).

Юл буендагы үләннәрне, куакларны сындырып үтсәң, юл буендагы кошларга таш атсаң, аларны куркытсаң, ояларын тузгытсаң – юлың уңмый. Аларның юл рухлары, юл ияләре, юл фәрештәләре булуы мөмкмн

Юлда төкеренеп барсаң – тиз хәлең бетәр, авыруга.

# Чабыр тау, Чабыр тау, Исемең мәңге калыр тау...

*Алсинә ӘХМӘТҖАНОВА,*
*Кама Тамагы, Келәнче авылы китапханәчесе*

**(XIV гасырдан алып Бөек Ватан сугышы башланганчы, Келәнче авылы җирлеге территориясендә Чабыр җыены уздырылган)**



Кама Тамагы районының Келәнче һәм Бәки авыллары арасында тирә-як халкын борын-борыннан үзенең сихри табигате, әлегә кадәр ачылып бетмәгән хикмәтләре, серләре белән тартып торган Чабыр тавы бар. Хуш исле чабыр үләне чәчәк атканда алсу, йә кызыл-шәмәхә төсләрдән җемелдәүче, май аенда, сары чәчәк (адонис) ачылганда сап-сары балкыш булып кабынучы Чабыр тавы сихри төсләргә күмелә.

Чабырның көньягында – текә яр. Ике канатны хәтерләтүче көнчыгыш һәм көнбатыш битләре исә сөзәк булып, ул тарафларда кайчандыр исәпсез-хисапсыз чишмәләр челтерәп аккан. Алар түбәнгә, Шакыян елгасына таба ыргылып, аның суын баетканнар, җиргә сеңеп, ямь-яшел баткак-сазлыклар хасил иткәннәр.

Тауны данлыклы иткән иң зур сәбәпләрнең берсе исә – биредә гасырлар буена ел саен Чабыр җыены уздырылган. Халыкның ике зур бәйрәме – Чабыр җыены һәм Сабан туе булган.

Чабыр җыены Бәки һәм Келәнче авыллары арасындагы тау башында – Чабыр тауда узган. Җәй көне, язгы кыр эшләреннән бушагач, Чабыр тавына тирә-яктагы утызлап авылдан авылдашлар, нәселдәшләр, туган-тумача, танышлар җыелган. Алар, атлар белән килеп, арбаларның тәртәләрен күтәртеп куеп, күләгәдә эскәтерләр җәеп табын корганнар. Әлеге табыннар тирәсендә хәл-әхвәл алышканнар, ил-көннең киләчәге белән бәйле мәсьәләләрне уртага салып сөйләшкәннәр, нәсел тамырларының ныклыгын кайгыртканнар. Чабыр җыены өч көн – 1 июльдән 3 июльгә кадәр дәвам иткән. Аларны «Чабыр башы көне», «Урта Чабыр көне», «Актык Чабыр көне» дип йөрткәннәр.

Чабыр җыенында ярышлар булмаса да, ат көче белән хәрәкәткә китерелгән ике-өч карусель эшләп торган. Ул балалар өчен дә, яшь-җилкенчәк өчен дә ел буе сөйли торган «Ат кәмите»енә әйләнгән. «Кызыл су» да, «Гәрәчи» дә шушы бәйрәмнең аерылгысыз бизәкләре булган.

«Гәрәчи» дип Чабырда сатылган камыр ризыгын атаганнар. Әче камырны суда изеп, казанда кайнап торган майга салып пешергәннәр. Җыенда базар оештырылган, тирә-яктан килгән кибетләр эшләгән. Бәйрәмгә баручылар сатасы әйберләрен сатарга алып барган, кирәк әйберләрен шунда караштырып йөргән. Биредә мал-туар да, ит тә, кием-салым да, эш кораллары да, орлыкка бәрәңге дә сатылган. Чабыр җыеныннан алып кайтып утырткан бәрәңге иртә өлгерә торган булган.













1941 елда Чабыр җыены соңгы тапкыр уза. Кайчандыр бабайлар яу чапкан тауда ир-егетләрнең күбесе соңгы тапкыр бәйрәм итә, аны соңгы тапкыр күрә...

2022 елдан башлап, район һәм җирле халыкның тырышлыгы, ярдәме белән Чабыр җыены яңадан торгызылды. Ул заманча формада үткәрелде. Әмма аның нигезен өлкән буынның хатирәләре һәм теләкләре тәшкил итте.

Чабыр җыенына алдан ук әзерләндек: тимерчелек хуҗасы Ринат Гомәров чәчәк рәвешендә һәм «Чабыр тау» дип язылган биек аркалы эскәмия эшләп бирде. Фотозона өчен бик матур урын булдырылды. Хәсиб Гайнуллин мәйданга тимер капка ясатып алып кайтты. Рәиф Вәлиев чишмә өчен самовыр эретеп ябыштырды. Авылыбызның үзешчән шагыйрәсе Фирая Ишморзина «Гасыр аша күрешү» исемле шигырь иҗат итте.

Элеккеге кебек үк бәйрәмгә безнең һәм күрше район авылларыннан, төрле шәһәрләрдән 2 меңгә якын кунак килде. Аларны Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты, Келәнче авылы егете Илдар Гыйльметдинов, район башлыгы Наил Вазыйхов сәламләде. Шул ук көнне җирле халыкның бердәмлеге һәм иминлеге символын гәүдәләндергән истәлекле ташны ачу тантанасы да узды.

Чара дәвамында район үзешчәннәре һәм килгән кунаклар тамашачыларны үз чыгышлары белән сөендерде.  Ринат Гомәров башкаруында бәйрәмнең гимнына әверелгән «Чабырлы тау» җыры (Фәйзерахман Зәйнуллин сүзләре, Айзат Шәйхелмәрданов көе) яңгырады. Балалар милли уеннарда, Антоновка авылы кешеләре үткәргән мастер-классларда бик теләп катнашты. Олылар өчен ат чабышы, бил-бау көрәше һәм башка ярышлар узды. Җиңүчеләр өчен кыйммәтле бүләкләр дә әзерләнгән иде.

Ярминкәләр дә оешкан төстә үтте: аш-су һәм кул эшләре осталары үзләренең товарларын халыкка тәкъдим итте. Ат арбасының тәртәләрен күтәртеп куеп, күләгәдә эскәтерләр җәеп табыннар корылды...

Бүгенгесе көндә иң изге бурычыбыз – үзебезнең туган якның тарихын тирәнтен өйрәнү, барлау, аны күз карасыдай саклау. Чабыр җыенын елның елында үткәрү. Чөнки аның әһәмияте бүгенгә буыннарга гына түгел, ә киләчәк өчен дә бик зур.

# ЧАБЫР ТАВЫ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

*Сиңа килдем, Чабыр тавым,*
*Сагынып килдем сиңа тагын*
*Тыңлар өчен серләреңне:*
*Кемнәр килеп уклар аткан,*
*Кем атлары монда чапкан,*
*Чатыр корып учак яккан,*
*Сагыш ягып дәва тапкан,*
*Исемнәрен белмәдеңме?*

*Чабыр, Чабыр, Чабыр тау,*
*Башны уйга салыр тау...*

*Чабыр тавы, Чабыр тавы*
*Чабып сиңа килдем тагын*
*Сөйлә әле серләреңне:*
*Үзәнеңнән чабып үткән,*
*Иңнәреңдә яллар иткән.*
*Итәгеңдә ярлар көткән,*
*Көтеп алган ярлар үпкән*
*Яшьлегемне күрмәдеңме?*

*Чабыр, Чабыр, Чабыр тау*
*Күпләр бәхет тапкан тау...*

*Чабыр тавы, Чабыр тавы,*
*Килдем әле сиңа тагын*
*Теләр өчен теләгемне:*
*Юллар сиңа туры булсын,*
*Адашканнар кайтып торсын,*
*Учак ягып дога кылсын,*
*Иңнәреңә башын куйсын*
*Тыңлар өчен серләреңне.*

*Чабыр тау, Чабыр тау,*
*Исемең мәңге калыр тау.*

**«Идел таңнары» газетасы һәм Лилия Кадырова фоторәсемнәре**




# «Изгеләр чишмәсе»

(«МИНЕМ ТАРИХ – МИНЕМ ТАТАРСТАН!» II БӨТЕНРОССИЯ БӘЙГЕСЕНӘ КИЛГӘН ЭШ)

*Минзәлия ЗӘЙНУЛЛИНА,*
*Балык Бистәсе, Иске Арыш авылы китапханәсе мөдире*



ИСКЕ АРЫШ АВЫЛЫНДА «ИЗГЕЛӘР ЧИШМӘСЕ»НЕҢ КӨМЕШТӘЙ ЧЕЛТЕРӘП АККАН САФ, ШИФАЛЫ СУЫН АВЫЛНЫКЫЛАР ГЫНА ТҮГЕЛ, ШӘҺӘР ХАЛКЫ ДА ЯРАТЫП ЭЧӘ. ӘЛЕГЕ СУНЫҢ БӨТЕН АВЫРУГА ДА ШИФАСЫ БАР ДИЛӘР. ҖӘЙ КӨННӘРЕНДӘ ШӘҺӘРДӘН КАЙТУЧЫЛАР «ИЗГЕЛӘР ЧИШМӘСЕ» СУЫН ХӘТТА ҮЗЛӘРЕ БЕЛӘН ДӘ АЛЫП КИТӘЛӘР.

Чишмә бик матур урында, ике тау арасында урнашкан. Аның як ягында үләннәр, камышлар үсә. Алар талгын җилдә акрын гына тирбәләләр, әйтерсең лә чишмә белән серләшәләр. Ә чишмә исә челтерәп агуын дәвам итә. Изгеләр чишмәсен казыган





игелекле җан иясе кем соң ул? Авыл картлары аның тарихын болай сөйли.

Моннан бик күп еллар элек, бу урында изге кешеләрне күмгәннәр. Озак та үтми, таулар арасында чишмә бәреп чыккан. Авыл картлары аны күреп, чистартканнар. Чишмә кыңгырау тавышлары чыгарып, челтерәп ага башлаган. Биредә күмелгән изге кешеләрнең рухлары авылны бәла-казадан саклаган. Ел саен аларга атап корбан чалганнар. Бу урынны «Изге җир» дип, ә чишмәсен «Изгеләр чишмәсе» дип атаганнар.

Бүгенге көндә дә чишмәне чистартып, карап, тирә ягын җыештырып торалар. Ә халык исә төркем-төркем булып, «Изгеләр чишмәсе»нең саф суын татып карарга агыла.

## «ИЗГЕЛӘР АШЫ» ЙОЛАСЫ

Һәр елның июль аенда чишмәбез янындагы болынлыкта «Изгеләр ашы» үткәрелә. «Изгеләр ашы»н үткәрү – борынгы бабаларыбыздан килгән күркәм йолаларның берсе. Ел саен чәчүләр беткәч, халык Ходайдан мул уңыш, күп итеп яңгыр теләп, авыл читендәге «Изге җир»дә дога кыла.

Иске Арыш авылының 900 елга якын тарихы бар. Зиратта күмелгән әрвахлар турында халыкта төрле сүзләр йөри. Риваятьләргә ышансаң, каберлектә туган җирен яклап сугышкан сугышчылар күмелгән. Иван Грозный гаскәренә каршы сугышкан изге җайдаклар каберлеге бу.

Явыз Иван сугышчылары авылны басып алмакчы булган. Тик ап-актан киенгән берничә җайдак каршы чыгып, аларны авылга кертмәгән. Кызганыч, үзләренең гомерләре яуда өзелгән. Сугыш вакытында да изгеләр рухына аш уздыру гадәте туктатылмаган. Элек атлар җигеп, тракторлар белән килгәннәр. Изгеләр рухына аш-су пешергәннәр, Коръән укыганнар, дога кылганнар.

Иртәдән кичкә кадәр үткәрелә торган дини бәйрәмнең үз тәртибе бар. Хатын-кызларга – көндез, ирләргә кич кенә килергә ярый. Шулай ук киенү тәртибенә дә зур игътибар бирелә. Әбиләр, апалар, ханымнар беркайчан да чәчен-башын тузгытып, кыска күлмәкләрдән килми. Башларында – яулык, өсләрендә – озын итәк булырга тиеш. Югыйсә укылган догаларның ияләренә барып ирешмәве бар.





Бу изге җирләр белән бәйле тагын бер риваять бар. Бик борынгы заманнарда бередә ак атка атланып сугыштан кайтып килүче өч җайдак үлеп кала. Авыл халкы аларны шушы урынга күмә. Мал-туар кермәсен, явыз кешеләр аяк басмасын дип, болынны рәшәткә белән уратып алалар...

Быел да авыл читендә урнашкан, әйләндереп алынган болынлыкта иртәнге алтыдан халык мәш килә башлады. Авыл халкы корбанлык өчен дип 41 баш сарык, 38 тавык биргән иде. Ирләр, Аллаһ ризалыгы өчен дип, кош-корт, сарыклар чалды. Берничә хатын-кыз тавык йолкып торды.

«Кайнар цех»ның пешекчеләре – ирләр. Болында бу эшкә хатын-кызны катыштырмыйлар. Уңган киленнәр иртән торып өйләрендә шулпага токмач кисеп киләләр. Аш-су әзерли торган учак янында зур утын әрдәнәләре өелгән. Мичкә белән су ташып торалар. Бер казанга дүрт сарыкның ите салына. Биш казанда да аш пешә. Беренче шулпа сәгать унга әзер була. Тирә-юньгә борынны кытыклап, тәмле, хуш исле шулпа исе тарала. Ике тонна аш халыкка таратып бетерелә. Күрше авыл халкы да килә. Һәммәсенә – якты йөз.

Учак исе сеңгән бу ашның тәме безгә балачактан таныш. Чөнки иртән әби-бабайларыбызга ияреп, без – балалар да, шул аштан авыз итәргә бара идек. Бала-чаганың күзе ризыкта булса, олылар бу көнне бик җитди була иде. Чөнки алар бабаларының изге рухына дога кылыр өчен килә.

Өйлә намазы җитәрәк, болынга абыстай килә. Ул вәгазьләр сөйли, дога укый. Соңыннан халык кыйбла ягына таба йөз тотып, намазга баса. Хатын-кызлар таралышкач, кичке якта җыенга ир-атлар килә.

Иң кызыгы, бу көнне күктә бер болыт әсәре булмаса да, ирләр намаздан кайтканда һәрвакыт яңгыр ява. Инде бер дә яумый дигәндә дә, күктән бер-ике тамчы таммыйча калганы юк. Яңгыр яуса, укыган догалар кабул була, ди авыл картлары.

Быел да, аш тәмамлануга, күк йөзен кара болыт каплады. Авыл халкы өчен җәйге челләдә яңгырдан да хәерле нигъмәт юк. Бездә аны Ходай рәхмәте буларак кабул итәләр.

Автор фоторәсемнәре

# *Бай күңелле Рифкать*

*Эшмәкәр Рифкать Шәфыйковны Теләчедә генә түгел, республикабызның башка районнарында да беләләр. Аның эшмәкәрлеге тумыштан. Теләчедә ул үз эшен, узган гасырның туксанынчы еллар башында, үзәк урамга сәүдә будкасы куюдан башлаган. Бүгенге көндә исә районыбызның иң күркәм җирендә урнашкан күңел ачу комплексы хуҗасы. Моның өстенә хәйриячелек белән дә шөгыльләнә. Чишмәләр төзекләндерә, ата-бабаларыбыз җәфа чиккән Суслонгер лагерына сәфәрләр оештыра, Коръән ашлары уздыра, ел саен ифтар мәҗлесләре үткәрә. Әлеге чараларга бик теләп балалары белән оныкларын да җәлеп итә.*

*Узган ел районыбызда «ТНВ-Яңа гасыр» телеканалы тарафыннан төшерелгән «Алмаш» сериалы Рифкать Зиатдин улын һәм аның «Туган авыл» күңел ачу комплексын бөтен дөньяга танытты. Дөнья буйлап сибелгән милләттәшләребез әлеге фильм аша районыбызны да яратты.*









### *Музейда – анын балачагы, яшьлеге*

*Әлбәттә, ялан кырда бөтен дөньяга танылырлык күңел ачу комплексы төзеп чыгу, аны тотрыклы эшләтү һәркемнең дә көченнән килми. Моның өчен сабырлык, үз эшенә, мәнфәгатьләренә фанатларча бирелгәнлек кирәк. Комплекстагы һәр почмак, һәр экспонат Рифкать абыйның үз тормышына, бигрәк тә балачак, яшьлек елларына, язмышына бәйле. Бу тәңгәллек бигрәк тә музей мисалында ачык чагыла. Бирәдәге экспонатлар турында ул сәгатьләр буе сөйли ала. Чөнки аларны кайчандыр эштә кулланган, шулар белән тормышын җайлаган. Экспонатлар артыннан вакытын, сәламәтлеген кызганмыйча, республикабыз читенә кадәр, хәтта чит өлкәләргә дә чыгып киткән. Башта ул аларны йорт ишегалдындагы алачыкта саклаган.*

*– Бирегә һәркем ашарга гына түгел, күңеленә рухи азык алырга да килсен иде. Хозурланырга бакчасы, күле бар, кызыксынган кеше музейны карый ала, – ди кафе хуҗасы.*

*Шунысы игътибарга лаек, музей экспонатлары көннән-көн артып, тулыланып тора. Бирәдә гасырлар аша килеп ирешкән тарих, мәдәният, безнең якка гына хас булган гүзәл табигать. Рифкать абыйга туган ягы газиз шул. Шулай булмаса, ул Теләче Сабан туена үзе кебек төбәк тарихы белән кызыксынучыларны чакырып китерер идеме?! Ул көнне без Сабантуйга керү мәйданында татар тормышының, мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булган самавыр, патефон ише көнкүреш кирәк-яракларына яңа сулыш өрүче (реставратор) Хәлим Гобәйдуллин (Кукмара), кул эшләре остасы, Кукмара районының Өлге авылы клубы мөдире Миләүшә Сәләхова һәм Бөтендөнья татар Конгрессы каршында эшләп килүче Төбәкне өйрәнү җәмгыяте Советы әгъзасы Олег Степанов тәкъдим иткән экспонатларны күреп тагын бер кат хозурландык.*






### *Бер дигән уку әсбабы*

*Музей түрендә Рифкать абыйның апасының кияүгә чыккандагы сандыгы тора. Пыяла эченә әтисенең сугышта йөреп кайткан блокноты куелган. Су-*





*гышка киткәнче үк, ул аңа иске татар язуы белән догалар язган булган. Польшада әсирлектә булганда да блокнотын саклап калган. «Үлгәндә дә кулында шушы блокнот иде, минем өчен иң кадерле әйбер бу», – ди Рифкать абый.*

*Музейда әнисе кулланган табагач, кисәү агачы, күмер алгыч та бар. Шунда ук чабаталар эленгән. Аларны Рифкать абый Балык Бистәсендәге бер остадан үрдерткән. «Уфалла» арбасын ул Кукмарадан алып кайткан. Бөек Тукайның 1943 елда басылып чыккан шигырьләр җыентыгы да саклана биредә. Быел музей тагын бер экспонат, Украинадагы махсус операциядән кыска вакытлы ялга кайткан районлашыбыз биргән пулемет гильзасы белән тулыланган. Аны автомат пулясы үтәли тишеп чыккан.*

*Әлеге музей мәктәп укучылары өчен бер дигән уку әсбабы. Биредә уку программасында, дәресләкләрдә булмаган мәгълүматлар, экспонатлар бихисап. Бу тарих әби-бабаларыбызныкы, безнеке. Тимерче алачыгы, авыл өендәге тукыма сугу станогы, музыкаль инструментлар бүлмәсе, хәрәкәт итүче поезд купесы – соңгы елларда гына булдырылган байлык. Моннан тыш, Ленин, пионерия тематикасы да комплекста аерым бер урынны биләп тора. Миңа әлеге экспонатларны бик күп кунаклар белән карарга туры килгәне бар. Соңгысында чит илләрдән, Россия төбәкләреннән килгән Сабантуй бәйрәмен оештыручы режиссерлар белән карарга насыйп булды. Комплексны күреп күбесе шаккатты. Бозаулы, бәрәнле кышкы авыл өен күргәч, патефонда әйләнүче пластинкадан Җәвәһирә Сәләхова, Зифа Басыйрова, Таһир Якупов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова җырлары яңгырагач, кайберәүләрнең күзендә яшь бөртекләре пәйда булды….*

***Мөлкәте белән генә түгел…***

*Рифкать абый тарих белән кызыксынучы эшмәкәр генә түгел, әйткәнемчә, танылган хәйрияче дә. Бу хакта аның туган авылы Олы Кибәчедәге чишмәләрне төзекләндерүе, аларны карап торуы, әнисе исемендәге җиде улаклы чишмәгә багышлап «Зөлхиҗә чишмәсе» җырын яздыртуы, мөмкинлекләре чикләнгән, ятим балаларны кунакка алып килеп күңелләрен күрүе, Сабантуйларында, 9 май – Җиңү көнендә авылдашларына концерт куйдыртуы сөйли…*

*Рифкать абый мөлкәте белән генә түгел, күңеле белән дә бай кеше. «Бай Рифкать» кушаматын бүгенгәчә лаеклы йөртә ул. Кушамат тагылуның тарихы болай. Заготконторда эшкә урнашкан еллары. Ул вакытта товар кибеткә түгел, заготконторага кайта торган була. Аңа кадәр эшләп киткән кеше, халык йомыш белән килгәч, ул: «Рифкатькә барыгыз, хәзер ул бай», – дип әйтә торган була. Шуннан аңа «Бай Рифкать» кушаматы ябышып кала.*

**Фәнил НИГЪМӘТҖАНОВ,**
**Теләче районы**

Автор фоторәсемнәре

# Миңгәр киче, таңы

**Наилә Яхина көе**
**Рифә Рахман сүзләре**




*Агымнарда – чуерташлар,*
*Дулкыннарда – йолдыз.*
*Ярның текә турысында*
*Йортын корган кондыз.*

***Кушымта:***
*Сандугачлар, чут-чут сайрап,*
*Айкый гына җанны.*
*Серле дә бик, моңлы да бик*
*Миңгәр киче, таңы.*

*Моңайганга – моңлыдыр ул,*
*Сер сөйгәнгә – серле.*
*Бөтен кошлар аңлый монда*
*Минем туган телне.*

***Кушымта.***

*Мишә буе – таллык кына,*
*Адым саен – чишмә.*
*Һәр чишмәнең бар үз күле*
*Агып җитәр төштә.*

***Кушымта.***

*Туган җирнең таңы бит ул,*
*Туган җирнең киче.*
*Һич үтмәс хис – Миңгәремә*
*Тарткан җирсү хисе.*

***Кушымта:***
*Сандугачлар, чут-чут сайрап,*
*Айкый гына җанны.*
*Серле дә бик, моңлы да бик*
*Миңгәр киче, таңы.*

# *Әкияти Хызрата*

*Саба җирлегендә серле дә, борынгы легендаларга да бай һәм шул ук вакытта заманча итеп төзелгән «Хызрата» исемле ял йорты комплексы бар. Ул Миңгәр авылына якын гына урнашкан. Аннан ерак түгел, калкулыктарак, «Сөембикә» манарасы кебек төзелгән, икенче ял йорты комплексы да эшли. Икесен дә шушы җирлектә – Миңгәр авылында туып үскән эшмәкәр Җәүдәт Миңнәхмәтов төзеткән.*

*Быел, җәй башында эшмәкәр «Хызрата» ял йорты комплексына Казаннан бертөркем язучыларны ял итәргә чакырып кайтарды. Моңа кадәр бу яклар турында аз-маз ишеткәнем булса да, барып төшкәч, күзгә чалынганы чишмәләр, чишмәләрдән җыелган күлләр булды. Сигез күл, текә таулык, тау битләрендә хисапсыз карлыгачлар... Алар шул тау битләренә «тәрәзәләр» уеп, оя корганнар. Түбәндә, тау елгасыдай шарлап, Мишә елгасы ага. Тау битләреннән дә чишмәләр бәреп тора. Минем мондый гаҗәеп матур табигатьне бер дә күргәнеп юк иде.*

*Шуларны күргәч,*
*күңелдә җыр юллары туды:*
*Карлыгачлар оя кора*
*Миңгәр тау битләренә!*
*Хызратада калалмамын,*
*Калалмам никләр генә?!*

***Кем ул – «Хызрата»?***

*Бу җиргә борынгы заманнарда Хозур Гата исемле изге кеше килеп урнашкан икән. Халык теленә исеме Хызрата булып кереп калган. Ул вафат булгач, күмгән җиреннән чишмәләр бәреп чыккан, имеш. Тау башында әле дә аның каберлеге бар. Аны биредәге җирле халык карап, чистартып тора. Ә инде узган-барган юлчылар, туктап, дога кылып китәләр. Без дә тау башына менгәч, тукталып, белгәннәребезне укып, Хозур Гата рухына дога кылдык.*

*Хызрата күленең тынычлыгына да шаккаттык. Әйтерсең лә монда вакыт тукталып калган. Аны кичләрен хәтта бакалар «симфониясе» дә уята алмый. Нindидер тирән уйлы күл сыман тоелды ул миңа.*

*Тау тирәләрен чорнап алган яшь наратлар урманы да сокландыргыч иде. Җәүдәт Миңнәхмәтов халыкны җыеп, ел саен меңләгән нарат утырттыра икән. Искиткеч! Бу кешеләрнең табигатькә булышуы бит! Кул сузуы!*

*Миңгәр табигатендә илһамланып йөри торгач, мин биредә ике җыр, бер шигырь иҗат иттем. Бүген шул җырларның берсен журнал укучыларына да тәкъдим итәм.*

**Наилә ЯХИНА,**
**композитор**

# Мөнәҗәтләр – җан авазы

*Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,*
*язучы, филология фәннәре докторы, Татарстанның, Россиянең атказанган фән эшлеклесе*

### ДИНИ МӨНӘҖӘТЛӘР

Төрле чорда һәм төбәкләрдә иҗат ителгән дини мөнәҗәтләрнең исемнәреннән үк күренгәнчә, барысы да югары шатлык хисе белән Аллаһны ихластан мактау-данлауга көйләнгәннәр. Бу төр мөнәҗәтләрнең нигезендә Аллаһтан җавап алу, ачыклау, көтелмәгән, җылы, ихласи эндәш-мөрәҗәгать ята. Охшаш сүз-гыйбарәләрне, чагыштыру-сынландыруларны кабатлаган өслүб битараф яки гадәти (түбән) сөйләмне кабул итми. Сүз – бөек, илаһи көч турында бара.

*Барча галәм юк чакта Ул бар иде.*
*Та әзәлдән бар иде, Җәббар иде.*
*Җен, фәрештә һәм адәм – берсе дә юк,*
*Һәм йәнә тугыз фәләк – һич берсе юк.*
(«Бердер Аллаһ, бердер»).

Яисә

*Гамәлне мизанга салган да Аллаһ.*
*Җәннәт капусын ачкан да Аллаһ.*
*Туры юлга күндергән дә Аллаһ.*
*Тәмуг утын сүндергән дә Аллаһ.*
(«Хак – хөкем кылучы – Аллаһ»).

Рамазан аеның соңгы ун көнендә мәчет-мәдрәсәләрдә, авыз ачу мәҗлесләрендә укыла, әйтелә торган «Әлвидагъ», мөнәҗәтләр арасында аерым урын били. Аңа бәя биргәндә, «Әлвидагъ, Әлвидагъ, Әл-Фирак, Әл-Фирак, Йә

(Дәвамы бар. Башы журналыбызның 2023 елның 1 нче санында)




**Россиядә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән җыентыкта төрле жанрдагы, шул исәптән дини һәм фәлсәфи, яшәү һәм үлем, сабырлык, ана һәм бала турында мөнәҗәтләр тупланды. Мөнәҗәтләр 2022 елда Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге хезмәткәрләре тарафыннан Әтнә, Буа, Казан, Аксубай, Саба муниципаль районнарына оештырылган фәнни-этнографик экспедицияләр вакытында язып алынды.**

Шәһри Рамадан» кебек сүз-гыйбарәләрнең кабатлана килүендә, гомумән мөнәҗәтләрнең әүвәл гарәп-фарсы телле ислам мәдәниятендә туганлыгына ишарә саклана. Татар мохитендә әлеге мөнәҗәтнең, аңа охшаганнарның саклануының бер сәбәбе исламны теләп кабул итү булса, икенчесе – алар үзебездә тәңречелек чорында туган келәү-алкышлар, кешене күмгәндә, бәла-каза килгәндә туган тезмә әсәрләр белән табигый рәвештә кушылып китүләрендә. Гарәп-фарсы мохитендә туган мөнәҗәтләр ислам диненең галәми (идеологик) нигез-өлгесенә утыртылганнар. «Кичер безне, Йә Аллаһ, Ля иляһа иллялләһ», дип мөэмин-мөселманнарның турыдан-туры Аллаһка мөрәҗәгате, ихластан теләкләр теләве, соңрак – мөнәҗәтләр догасы буларак исламны кабул иткән һәр халыкның үз телендә башкарылганнар. Тик гомуми мөрәҗәгатьләрдә генә гарәп-фарсы алынмалары сакланган. Һәр очракта да (күп теллелектә дә) суфыйчылыкның нигезендә яткан гүзәллекнең чыганагы Аллага платоник-гыйффәтле гашыйклык үзәктә торган. Алланы, аның җирдәге илчесе Мөхәммәдне сөю фани дөньяда ук мәңгелек рәхәткә ирешү. Ислам кабул иткән инсан әүвәл «Көндезләрен уразада, Кичләрен без намазда», дип кат-кат кабатлап хисап тотса да, «Кичер безне, Йә Аллаһ», дип ярлыкавын сорап, үтенеп торудан тайчынмый. «Әлвидагъ» югары өслүбтә «төшерелгән» булса да, дин, ураза тотуның да үз гамәлләре, гадәти төшенчәләр турында да уйланырга мәҗбүр итә.

### «ӘЛВИДАГЪ» МӨНӘҖӘТЕ

*(Рамазан аеның соңгы ункөнлегендә укыла)*

*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Коръән иңде бу айда*
*Нурлар иңде бу таңда*
*Ашкын-ашкын, әй бәндә*
*Изгелекләр эшләргә*
*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Рамазанның башында*
*Һәрбер бәндә каршына*
*Фәрештәләр иңәрләр*
*Гонаһтан котыл,*
*әй бәндәм диярләр.*
*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Рамазан айларында*
*Шайтаннар богауланыр*
*Һәрбер бәндә каршында*
*«Раян» ишеге ачылыр*
*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Ля иляһа иллялләһ*
*Мөхәммәдурәсүлләһ.*

Мөхәммәд пәйгамбәрнең дөньяга килүенә багышланган «Мәүлид» мөнәҗәте күләме, гарәп-фарсы лөгатьләреннән кереп калган сүз-гыйбарәләрнең күплеге ягыннан да башкалардан аерылып тора. Ул шәрыкъ әдәбиятында калыплашкан тәүхид (гарәп атамасы – бер итү, берләштерү) жанрында язылган. Әүвәл, монотеистик мәүзугъка, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәргә кучкәнче, Алланың берлегенә, гадел бөеклегенә, дөньяны яратуына дан җырлана. «Әүвәл Аллаһ исемен зикер итәем» һәм шуннан соң

гына «башка эшемә керешәем», ди мөнәҗәтче, башкаларны да шулай эшләргә, яшәргә чакыра. Башка мөнәҗәтләрдә әйтелгән, Аллаһ кылган бөек гамәлләрне санап китә.

*Һәм өзәлдән бай иде, Җаббар иде.*
*Җен-фәрештә һәм адәм берсе дә юк.*
*Һәм янә тугыз фәләк һичберсе юк.*

Бер Ходай юктан бар итте дөньяны дип, ошбу фикерен кат-кат кабатлаганнан соң, бер васыять сөйләргә вәгъдә итә һәм исемгә чыгарылган «Мәүлид» сүзенә – мәгънәсенә әйләнеп кайта. Дөньяны юктан бар иткән Аллаһның җирдәге илчесе – яраткан нәбие Мөхәммәд пәйгамбәргә күчә. Мөхәммәднең атасы Габдулланы, анасы Әминәне рәхмәт нурында коендыргач, «инде аның килүе булды ул, бер гаҗәп нур, нәкъ кояшның яктысы булды», дип үзенең шатлыгын белдерә. Мөнәҗәтче сөекле пәйгамбәребезнең тууын кешелек уйлап тапкан иң сөенечле мактау сүзләренә, мәдхияви гыйбарәләргә төреп бирә. Мәсәлән, иҗатчы-сөйләүче янына килеп утырган өч хур кызы: «Мостафа килә!» – диеп гәп коралар. Аның бөек шәхес, гыйльми дәүләтнең солтаны булачагын әйтәләр. Төп фикерен тыңлаучыга «Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез», дигән үтенечен соңгы юлларда әйтеп калдыра.

## МӘҮЛИД

*Әүвәл Аллаһ исемен зикер итәем*
*Соңра башлап һәр эшкә керешәем!*
*Эш башында кем аны зикер итәр*
*Ул эшен Аллаһ аңа ансат итәр*
*Аллаһ исемен зикер итеп эш башламак*
*Һәркемгә вәҗип тиештер аңламак*
*Булса Аллаһ исеме белән һәр эшең*
*Бушка китмәс эшләгән һәрбер эшең!*
*Шул илә Аллаһ дисә кемнең теле*
*Барча гөнаһы түгелер яфрак кебек.*
*Пакъ булыр Аллаһ исемен зикер иткән*
*Ирешер максадына Аллаһ дигән.*
*Килегез чын күңелдән Аллаһ диик*
*Күзләрдән яшьләр түгеп без аһ итик.*
*Шулай итсәк буш куймас Аллаһ безне*
*Рәхмәте киң, ярлыкар һәммәбезне.*
*Бердер Аллаһ, берлегенә шөбһә юк...*

*Диде Әминә вакыт җитте тәмам,*
*Килә инде дөньяга хәйрел – әнәм.*
*Эсселектән сусадым гаять каты*
*Шул вакыт эчерделәр бер ширбәтин.*
*Ап-ак иде кардан да салкын иде*
*Бу кеби дөньяда һич юк иде.*
*Эчтем аны барлык әгъзәм булды нур*
*Эчмәгән тышым атылды нур*
*Килде бер аккош канат илә очып*
*Аркамнан ул сыйпады монда төшеп.*
*Туды шул сәгатьтә ул солтан идең*
*Нурга тулды барлык сәмәват-зәмин.*
*Гәрчә шәфәгать кирәк исә эзләгез,*
*Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез.*
*И Мөхәммәд Мостафа син, и Рәсүл,*
*Кыл шәфәгать безләргә яумин-нәүзүн.*
*Гәрдәләр сез буласыз уттан нәҗәт*
*Гыйшык илә, дәрт илә әйтик «Салават»...*

Шул рәвешле, дини мөнәҗәтләр Коръән, аны тәфсилләүче мәгълүматларга, мифологиягә, телдән-телгә күчә килгән хатирәләргә, милли аң рудиментларына таяналар. Күп очракта хыял уены, эчке вә мантыйк сиземләү, иҗатчының фикерләү сәләте, дини-гыйльми әзерлеге әһәмияткә ия. Иң камил мөнәҗәтләр фарсы, гарәп, саф татар телендәгеләре Утыз Имәни, Мәүлә Колый, Шәмсетдин Зәки, Акмулла, Кандалый каләмнәре казанышы (алданрак искәртелгәнчә, хәзерге сүз осталары да мөнәҗәтне рухи дөньяны психологик нечкәлек белән ачуның иң ышанычлысы саныйлар). Дини мөнәҗәтләрнең структур-композицион үзенчәлеге әһәмияткә ия. Аларда еш кына «икеләтелгән проекция» алымы кулланыла, иҗатчы әүвәл «читтән торып» олы затларга мәдхия яудыра, соңгы юлларда үзенең барлыгын исенә төшереп, гөнаһларын ярлыкауны, шәфкать көтүен әйтеп тәмамлый. Ул тар эгоист түгел, үтенечен барча мөселман кардәшләре исеменнән әйтә. Адәм балаларының бар авырлыкларга түзүенә хыялында йөрткән оҗмах ләззәтләренең якты нуры балкып торуы ярдәм итә. «Әманәт», «Иярмәк тиештер сөннәткә», «Потлар егылган бу көн», «Барча инсан нигә шатлана?», «Әйтик әле салаватны», «Хак дингә багышланган гомер» һәм башкалар. Биредә атап үтелгән классик мөнәҗәтләр һәр инсанны фанилыкта дөрес яшәргә, башка дөньяга әзерләүче гамәлләре шактый уйланылган булуга чакыра.

# «Әх, авылым кичләре»

(ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ ӨЧЕН)

*Розалия ШӘЙДУЛЛИНА,*
*Арча «Үрнәк» балалар бакчасы*
*музыка җитәкчесе*



*(Матур итеп бизәлгән зал. Бер якта – авыл өе макетлары, икенче якта – болын. «Туган як кичләре» (А. Ключарёв көе, Г. Зәйнашева сүзләре) җыры яңгырый. Эскәмиядә кызлар кулъяулык чигә. Кызлар янәшәсендә күрше әби дә утыра.)*

**Әби:** Яшь чагында без дә шулай җыела идек. Егетләр килә иде, бергә уеннар уйнап, җырлар җырлап, биюләр биеп күңелләребезне күтәрә идек. Рәхәт чаклар бар иде!

**Алсу:** Әбекәй, безгә дә биеп күрсәт әле.

**Әби:** Юк, юк, хәзер аякларым да бик йөрми...

**Кызлар:** Биеп күрсәт инде, әбекәй.

*(Әби татар бию көенә бии.)*

**Адилә:** Кызлар, әйдәгез без дә, әбигә кушылып, биеп алыйк.

*(Кызлар да биюгә кушыла. Гармун тавышы ишетелә. Кызлар биюдән туктый. Җырлый-җырлый егетләр керә.)*

**Егетләр:**
Эх, сез, матур кызлар,
Ник шаяртасыз?
Йөрәгемнең януларын
Аңламыйсыз.
**Рамил:**
Исәнмесез, саумысыз!
Нигә кәҗә саумысыз?
Әтәчегез кукәй салган,
Нигә чыгып алмыйсыз?
**Алсу:**
Әй, әпсәләм, әпсәләм.
Сәлам бирдем:
– Әссәлам!
Синнән безгә тиештер бит,
**Егетләр:** Вәгаләйкемәссәлам!

*(Кара-каршы җырлыйлар.)*

**Егетләр:**
Чептәр элдем читәнгә,
Җилфер-җилфер итәргә,
Без килмәдек буш китәргә,
Килдек алып китәргә.
**Кызлар:**
Алын алырсың микән,
Гөлен алырсың микән?
Урталарга чыгып сайлап,
Кайсын алырсың микән?
**Егетләр:**
Алларын да алырбыз,
Гөлләрен дә алырбыз.
Күңелебезгә кем ошаса,
Шунсын сайлап алырбыз.

**Әби:** И-и, балалар, килүегез бик әйбәт булды әле, кызларның да күңеле булыр.

**Гөлназ:** Малайлар, кызлар! Әйдәгез, биеп алабыз.

*(«Сигезле бию» биилэр.)*



**Адилә:** Арып китмәдегезме әле?
**Булат:**
Юк, без арымадык әле,
Бу көн безнең тантана.
Гармунчы уйна бер көйне
Хәзер уен башлана.

*(«Түбәтәйле» уенын уйныйлар.)*

**Илнур:** Әйдәгез такмаклар әйтешәбез.
*(Такмак әйтә.)*
Такмакка да мин оста,
Шакмакка да мин оста.
Әти-әни эшкә кушса,
Мин авыру, мин хаста.
**Алия:** *(Кулында сөлге.)*
Сөлге сугам, сөлге сугам,
Сөлге сугам аклыкка.
Кызыл башлы сөлгеләрем
Язсын бәхет-шатлыкка.

**Камил:** *(Кулында уенчык гармун.)*

Гырмафунны көйләр идем,
Көе беткән көйләргә.
Сез кайдагы бай кызлары
Сайлап егет сөяргә?

**Булат:** *(Як-якка карангалый.)*

Тәрәзәңә карар идем,
Тәрәзәңә боз каткан.
Кунак кызың ялкау икән
Сәгать сигездә яткан.

**Лилия:**

Иртән торып эшкә чыксам,
Кәҗәләр кар көриләр.
Чикерткәләр туфли киеп,
Җырлап-биеп йөриләр.

**Алсу:** Аргы төркемнән килдеңме,
Бирге төркемнән килдеңме?
Без сагынганны белдеңме,
Үзең сагынып килдеңме?

**Барысы бергә:**

Ал да булыр чагыбыз,
Гөл дә булыр чагыбыз.
Без җырламый кем җырласын,
Безнең җырлар чагыбыз.

**Әби:** Балалар, безнең заманнарда табышмаклар да әйтешә идек, минем табышмакны тыңлагыз: башы – мунча, койрыгы – сүс.

**Камил:** Себерке.

**Әби:** Юк, белмисез. Ул чабата. Элек безгә әтиләр чабата үреп бирәләр иде дә, төшеп калмасын дип, артына сүс бау тагалар иде.

**Илнур:**

Минем дә табышмагым бар:
Сырлы, сырлы, сырлы ул,
Безнең белән җырлый ул.
Биетә дә, җырлата,
Күңелле ул, моңлы ул.

**Алия:** Гармун! Ә минем табышмакның җавабын таба алмассыз:

Озын-озын агачлар,
Агачларда оялар,
Ояларда кошчыклар.

**Булат:** Кыяр.

**Алия:** Юк шул, борчак. Кызлар, нинди җәза бирәбез?

**Лилия:** Әтәч булып кычкырсын.

*(Булат әтәч булып кычкыра.)*

**Салават:** Минем табышмакның да җавабын таба алмассыз:

Тәртәсе бар, аты юк,
Күзләре бар, башы юк.

**Адилә:** Рәсем микән, түгелдер...

**Салават:** Белмисезме? Күзлек ул. Адиләгә нинди җәза?

**Егетләр:** Җырласын.

*(Адилә «Әбием» (Ф. Зарипова сүзләре, С. Сабирова көе) җырын башкара.)*

**Алсу:** Егетләр, кызлар, элек бит җырлап, биеп, уйнап кына уздырмаганнар кичләрне. Шулай бит, әбекәй?

**Әби:** Әйе, кызым, җырлап-биеп кенә түгел, кышкы кичләрдә без чигеп, бәйләп утыра идек (кулындагы сөлгене күрсәтә). Менә мин чиккән сөлге. Менә бу – чиккән алъяпкычым (кигән алъяпкычын күрсәтә). Татар кызларының алъяпкычлары канатлы булырга тиеш. Менә – күкрәкчә *(кигән күкрәкчәсен күрсәтә)*. Ул бит бизәнү әйбере генә түгел, хатын-кызларның күкрәген ят күзләрдән дә саклаучы. Менә бу чуклы калфакны да мин үзем чиктем *(калфагын күрсәтә)*.

**Алсу:** Әбекәй, калфагыңны киеп карыйм әле.

*(Калфагын кия дә бии башлый. Кызлар-егетләр да аңа кушыла. Әтәч кычкыра.)*

**Алия:**

Тартып уйна гармуныңны,
Күтәрелсен күңелләр.
Күтәренке күңел белән
Үтсен безнең гомерләр!

**Булат:**

Дуслык җебе өзелмәсен ул
Моңлы халык бар җирдә,
Безнең шушы очрашулар
Истә калыр гомергә.

*(Егетләр, кызлар бергә «Дустым бар» (Л. Хисмәтуллина көе һәм сүзләре) җырын башкаралар.)*

# Көзбай агай

Наилә Яхина көе
Рәхимә Арслан сүзләре




*Коеп агач яфракларын,*
*Бер моңайды, бер көлде.*
*Мул уңышына куанып,*
*Кыр-басуларда йөрде.*

***Кушымта:***
*Кызгылт-сары төскә манып*
*Урман һәм болыннарны,*
*Килеп җитте Көзбай агай,*
*Кисәтеп кош-кортларны.*

*Вак яңгырлар сибәләде,*
*Ялангач калды кырлар,*
*Кошлар җылы якка очты,*
*Тукталды моңлы җырлар.*

***Кушымта:***
*Кызгылт-сары төскә манып*
*Урман һәм болыннарны,*
*Килеп җитте Көзбай агай,*
*Кисәтеп кош-кортларны.*

ЭРЕМЧЕК ПИЛМӘНЕ – ЭЧЕ ЭРЕМЧЕКЛЕ, ТЫШЫ ТӨЧЕ КАМЫРДАН БУЛГАН ВАК БӨККӘН. УЛ КАЙНАП ТОРГАН СУГА САЛЫП ПЕШЕРЕЛӘ. РУСЛАРДА ЭРЕМЧЕК ПИЛМӘНЕ «УШКИ» – ВАРЕНИКИ ДИП АТАЛА.
ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШЛӘРДӘ ПИЛМӘН СҮЗЕНЕҢ ФОНЕТИК ВАРИАНТЛАРЫ, МӘСӘЛӘН, БИЛМИН, ПИЛМИН – КРАСНОУФИМ ТАТАРЛАРЫ СӨЙЛӘМЕНДӘ; ПИЛМИН – МИНЗӘЛӘ; ПИЛМИНЧӘ – СЕРГАЧ; ТИРМӘНКӘ – ЧИСТАЙ СӨЙЛӘШЕНДӘ КУЛЛАНЫЛА.

Татарханә

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Рубриканы «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара.

# КАЗАН кәлҗемәсе







## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Камыр өчен:**
1 стакан он,
1 данә йомырка,
2 аш кашыгы шулпа,
тәменчә тоз.

**Эчлек өчен:**
2 литр су,
200 грамм эремчек,
1 данә йомырка,
2 аш кашыгы каймак,
тәменчә тоз.



1 Кирәкле ингредиентларны алдан әзерләп куябыз. Шулпага йомырка, тоз, он салып, йомшак кына камыр басабыз.





2 Камыр ял иткән арада эчлек әзерлибез. Иң элек эремчекнең суын саркытып, иләк аша кашык белән уабыз яки иттарткычтан чыгарабыз. Аннары аңа йомырканың сарысын, каймак, тоз салып, болгатабыз.




3 Эремчек пилмәненә камырны токмач камыры кебек итеп бассак та, җәемен калынрак җәябез һәм 6-7 сантиметр диаметрдагы түгәрәкләргә кисәбез.



4 Эремчектән ясалган әзер эчлекне түгәрәк уртасына салып бөклибез, кырыйларын ябыштырып, бөреп чыгабыз.



5 Пилмәннәрне кайнап торган тозлы суда пешерәбез. Пешеп чыккач, судан тишекле чүмеч белән сөзеп алабыз.



6 Табынга кайнар килеш шулпа, каймак яки катык белән бирәбез.

**Ашларыгыз тәмле булсын!**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
2023

## ОКТЯБРЬ

**1 октябрь**

Халык музыка уен коралларында уйнау остасы, ТАССРның атказанган артисты Фәйзи (Фәйзерахман) Бикмөхәммәт улы Биккининнның тууына 125 ел (1898-1968)

**5 октябрь**

Шагыйрә Зәйнәп Хуҗихан кызы Бәшированың тууына 120 ел (1903-1984)

**13 октябрь**

Рәссам, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мөдәррис Мөхетдин улы Минһаҗевка 70 яшь (1953)

**20 октябрь**

Дирижёр, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Әзһәр Хәниф улы Абдуллинның тууына 100 ел (1923-1993)

**20 октябрь**

ТАССРның атказанган артисты Асия Әхмәтша кызы Харисованың (Разаутдинова) тууына 100 ел (1923-2011)

**20 октябрь**

Рәссам, график, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Булат Шаһинур улы Мордановка 70 яшь (1953)

**26 октябрь**

Скрипкачы, педагог, профессор, ТАССРның атказанган артисты, Халыкара конкурслар лауреаты Зариус Госман кызы Шаһморзаеваның тууына 90 ел (1933-2010)

**27 октябрь**

Актёр, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Раушан Тимерҗан улы Шәриповка 60 яшь (1963)

## НОЯБРЬ

**1 ноябрь**

Драматург, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Риза Фәхретдин улы Ишморатның (Ишморатов) тууына 120 ел (1903-1995)

**6 ноябрь**

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры (элеккеге Татар дәүләт республика күчмә театры) оештырылуга 90 ел (1933)

**12 ноябрь**

Татарстан Республикасының халык артисты Идрис Мәдәррис улы Мәсгутовның тууына 75 ел (1948-2008)

**13 ноябрь**

Актриса, ТАССРның халык артисты Мөнирә Габдулла кызы Шаһидуллинаның тууына 100 ел (1923-2001)

## ДЕКАБРЬ

**1 декабрь**

График, нәкышче, педагог Җәгъфәр Гыйззәт улы Булатның тууына 120 ел (1903-1981)

**1 декабрь**

Актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Исламия Һидиятулла кызы Мәхмүтованың тууына 80 ел (1943-2019)

**3 декабрь**

Рәссам, график, ТАССРның халык рәссамы һәм атказанган сәнгать эшлеклесе Гайшә Габдрахман кызы Рахманкулованың тууына 110 ел (1913-1991)

**6 декабрь**

Актриса, Татарстан Республикасының халык артисты Раушания Самат кызы Фәйзуллинага 60 яшь (1963)

**10 декабрь**

Язучы, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Сафа улы Мөхәммәдиевкә 75 яшь (1948)

**13 декабрь**

ТАССРның атказанган артисты Каюм Барый улы Бариевның тууына 125 ел (1898-1976)

**14 декабрь**

Скрипкачы, дирижёр, педагог, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Ибраһим улы Үтәйгә 80 яшь (1943)

**15 декабрь**

Актриса, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Бикә Шакир кызы Шакированың тууына 100 ел (1923-1996)

**22 декабрь**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Ленар Рәис улы Гыйльметдиновка 60 яшь (1963)

**23 декабрь**

Этнограф, Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты Рәмзия Гыйният кызы Мөхәммәдованың тууына 100 ел (1923-2020)

**25 декабрь**

Актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Фатыйма Хәйрулла кызы Камалованың (Хәлиуллина) тууына 120 ел (1903-1974)

**28 декабрь**

Театр белгече, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәсән Хәйрулла улы Гобәйдуллинның тууына 110 ел (1913-1992)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**

**Кадерле укучыларыбыз!**
2023 елның икенче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 283 сум 39 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 566 сум 78 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!